БАЕТАМЫ, БӨЛДЕРӘМЕ?

«ВТ» хәбәрчесе онлай сату һәм сатып алуның ни өчен популяр булуын ачыклады

> 6

ЧИКСЕЗ ЧИРАТ

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына урын көткән сабыйлар күпме?

> 15

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА:

«Безнең буында туган илгә мәхәббәт көчле»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 16 (28983) | Җомга | 3 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

НИГЕЗ КАДЕРЕ

ХУҖАСЫЗ ЙОРТЛАР АВЫЛНЫҢ ЯМЕ БЕЛӘН РУХЫН ДА АЛА

Һәр авылда да диярлек җиргә сеңеп барган хуҗасыз йортлар бар. Хәер, аларны иясез дип әйтү бик үк дөрес тә булмас. Кайдадыр бар инде аларның хуҗалары, тик нигезне кайтып караучысы, тәрбияләүчесе генә юк. Шул ук вакытта авылны ямьсезләп торучы әлеге иске, ярым җимерек хәлдәге йортларга тияргә дә ярамый. Моны хәл итү юллары бармы? Кадерсез йортлар һәм алар тудырган проблемалар турында сөйләштек.

> 5

Ишетми калмагыз

Татарстанда иң кирәкле һөнәр ияләре – машина йөртүчеләр, электр-газ белән эретеп ябыштыручы, кондуктор, механик-җыю эшләре слесарьлары. Шулай ук сәламәтлек саклау өлкәсенә санитарка, шәфкать туташлары җитми. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова әйтүенчә, узган елның катлаулы булуына, күп кенә компанияләрнең Россиядән китүенә карамастан, мәшгульләр саны гына түгел, вакансия буенча тәкъдимнәр дә сакланып калган. Министр сүзләренә караганда, хәзерге вакытта эшсезлек тә моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә – нибары 0,36 процент (7,2 мең кеше). 43 мең буш эш урыны бар. Шул ук вакытта Татарстанда яшәүчеләр үзләре йөртүче, менеджер эшләрен ешрак эзли икән.

Казан башкарма комитеты 50 ел (алтын туй), 60 ел (бриллиант туй) һәм 70 ел (таҗлы туй) бергә яшәүче гаилә парларына акчалата бүләкләр әзерләгән. 50 ел пар канатлар булып яшәүчеләргә быел – 6 мең сум, 60 ел бергә яшәүчеләргә – 10 мең, 70 ел кулга-кул тотышып гомер кичерүчеләргә 25 мең сум биреләчәк.
Узган елда юбилейларын билгеләп үткән парларга да бүләк тапшырылачак: алтын һәм бриллиант туйларын уздыручыларга – 3 мең сум, таҗлы туйларын уздыручыларга – 5 мең сум күләмендә.
Бүләк алу өчен ирнең дә, хатынның да Россия гражданнары булулары һәм Казанда яшәүләре кирәк. Шул ук вакытта никах та Татарстан башкаласында теркәлгән булырга тиеш.

Полиция хезмәткәрләре Кайбыч районының Мөрәле авылындагы ангарда нарколаборатория тапкан. 3 кеше тоткарланган, 13,8 кг авырлыктагы синтетик наркотик кулга төшерелгән. Эчке эшләр министрлыгы матбугат хезмәте хәбәренә караганда, полиция хезмәткәрләре ангарда наркотиклар, лаборатория җиһазы һәм тыелган матдәне әзерләү өчен прекурсорлар тапкан. Экспертиза биредә табылган 10,3 кг авырлыктагы матдәнең синтетик наркотик икәнлеген күрсәткән. Моннан тыш Югары Ослан районының Юмат авылындагы урманда яшерен урыннан 3,5 кг авырлыктагы наркотик табылып, монысының да тоткарланган ир-атларныкы булуы ачыкланган.

Ял көннәрендә Татарстанда аз гына кар көтелә. Көндез һава температурасы –9 градус, төнлә –19 градуска җитәргә мөмкин. Республика Гидрометеоүзәге мәгълүматларына караганда – 4–5 февральдә көндез –3...–9, төнлә –7...–14, урыны белән –19 градуска кадәр салкын булыр дип фаразлана. Гидрометеоүзәкнең башлангыч фаразларына караганда, киләсе атна башында кайбер районнарда аз гына кар явып үтәчәк. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –5...–12 градус чикләрендә тирбәлсә, төнлә –10...–15, урыны белән –20 градуска кадәр төшәчәк. Сүз уңаеннан, КФУның Экология һәм табигатьтән файдалану институты белгече Тимур Әүхәдиев әйтүенчә, февральнең беренче декадасында температура нормадан (норма –11 градус чамасы тәшкил итә) 3–4 градуска югарырак булуы көтелә.

Районнарда ни хәлләр?

Әлмәт

Ел башыннан Әлмәт районында 164 үсмер паспорт алган. Гыйнвар азагында Эчке эшләр министрлыгының район бүлеге һәм Әлмәт драма театры яшүсмерләр өчен акция әзерләгән. Паспорт алучыларга «Пушкин картасы»на сертификат та бирелә. Яшьләр күргәзмәләргә, музейларга һәм театрларга бушлай йөри ала. «Анда билет алу өчен «Пушкин картасы»н ничек алырга кирәклеге аңлатылган, афиша белән танышу һәм билет алыр өчен куаркод бар», – дип сөйләде Әлмәт драма театры директоры урынбасары Гөлназ Гыйззәтуллина.
(«Әлмәт таңнары»)

Түбән Кама

Түбән Каманың Габдулла Тукай исемендәге Үзәк китапханәсендә «Вәт өчпочмак» проектының беренче очрашуы булды. Аның кысасында язучылар, җырчы-башкаручылар, композиторлар белән очрашулар уздырачаклар. Беренче очрашу 13 китап, 200дән артык җыр текстлары авторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган табибы Марс Хафизов белән узды. Әдәби очрашу барышында аның сүзләренә язылган көй авторлары – композиторлар белән дә әңгәмә кордылар. «Илһам» җыр эстрада артистлары әлеге җырларны тамашачыга җиткерде.
(Tatar Life)

Сарман

Районда дүртенче мәртәбә кышкы балык тоту ярышы узды. Быел Шыгай авылында оештырылган чарада «иң яшь балыкчы» булып Тимерхан Латыйпов танылды. 80 яшьлек Илгиз Исмәгыйлев «Иң өлкән балыкчы» буларак бүләкләнде. Шәмсемөхәммәтовлар бөтен гаиләләре белән балык тотарга килде. Алар да махсус призга ия булды.
Хатын-кызлар арасында иң күп балык тотучы булып Дружбадан Ләйлә Долгунова танылды. Ир-атлар арасында Радик Сәгыйтов иң остасы иде. Иң зур балыкны гомер буе урманчы булып эшләгән Рашат Мортазин тотты. Иң кечкенә 5 граммлы балыкны Иршат Гыйльфанов каптырды.
(«Сарман»)

Саба

Ел ярым чамасы элек танылган рәссам Фәйзрахман Камалов Миңгәр авылына кайтып төпләнеп, иске мәктәп бинасында остаханә булдыра һәм иҗат белән шөгыльләнә башлый. Хәзер остаханә тантаналы төстә ачылды.Тантанада Фәйзрахман Камаловның улы Ильясның виолончель, кыл-кубыз кебек үзенчәлекле уен коралларында уйнавы сокландырды. Ильяс Камал – яшь композитор, Тинчурин театрының баш дирижеры, Россия һәм Татарстанның Композиторлар берлеге әгъзасы. Шулай ук чарада кыл-кубыз һәм башка уен кораллары ясаучы Җәлил Вилданов, Мөдәррис Минһаҗев, татарның танылган актеры Шәүкәт Биктимеровның кызы Гүзәл ханым катнашты. Иске мәктәп бинасында рәссамнар һәр атнаның җомга көнендә мастер-класс үткәрә.
(«Саба таңнары»)

БЕРЕНЧЕ ОЧРАШУ

Мәскәүдә «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумына әзерлек һәм аны үткәрү турында сөйләштеләр. Оештыру комитетының Россия Хөкүмәте вице-премьеры Марат Хөснуллин рәислегендә узган утырышында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Искәртеп үтик: Россия Президенты Владимир Путин карары нигезендә Казандагы форумга федераль статус бирелде. Марат Хөснуллин сүзләренчә, илнең социаль-икътисадый үсеше турында сөйләшкәндә төрле яклы мөнәсәбәтләрне ныгыту төп рольне уйный.

– Россия мөселман илләре белән элемтәне арттыруын дәвам итә, – диде ул. – Бу элемтәләр яңа перспективалар ача дип әйтеп була. Без ислам дәүләтләре ягыннан ярдәм тоябыз, аларның безнең позициягә тирәнтен аңлавын һәм конструктив хезмәттәшлеккә ачык булуларын күрәбез. «KazanForum» уникаль мәйданчык санала.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Россия белән ислам дөньясы арасында үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерү – ил җитәкчелеге тарафыннан билгеләнгән өстенлекле юнәлешләрнең берсе. Икътисадый хезмәттәшлекнең төп мәйданчыгы да – Казандагы форум.

– «KazanForum» чарасына ил Президенты йөкләмәсе буенча мин җитәкләгән «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме алып барган зур эшнең мөһим өлеше буларак карыйбыз, – диде Татарстан Президенты.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, булачак форумның эшлекле программасын төзү буенча эш алып барыла. Президент искәрткәнчә, форум югары дәрәҗәдә оештырылачак.

КУРКЫНЫЧ МАШИНА

Рульгә кемнең исерек килеш утырганын барысы да белсен! Хөкүмәт йортында узган утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та әнә шулай диде. Биредә юл иминлеге һәм куркыныч саннарны киметү турында сөйләштеләр. Узган ел республика юлларында 306 кешенең гомере өзелгән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Министрлар Кабинеты һәм Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының уртак утырышында министр Артем Хохорин республикада соңгы биш елда юл фаҗигаләре саны кимесә дә, юлдагы вазгыятьнең тотрыксыз булып калуын әйтте. Былтыр Татарстан юлларында 3317 авария булып, 306 кешенең гомере өзелгән, 4095 кеше имгәнгән. Татарстанның 14 районында юлда үлем-китем очраклары арткан.

Артем Хохорин сүзләренә караганда, юл корбаннары арасында өлкән яшьтәге кешеләр күбрәк. Аларның күбесе караңгыда каршына килеп чыккан машинаны күреп бетермәве аркасында харап була. Шуңа күрә министр юлчыларга юл читләрен яктыртырга һәм тротуарларны тәэсезләндерергә кушты. Былтыр, мәсәлән, федераль трассалардагы нибары өч җәяүле кичүе яктыртылган. Тагын 101е үз чиратын көтә. Фаҗигаләр саны артуга юлларның тар булуы да сәбәпче.

Юлдагы үлем-китем очраклары артуга һаман да шул каршы як полосага чыгып хәрәкәт иткәндә, юл кагыйдәләрен бозу да гаепле. Узган ел шуның аркасында Татарстан юлларында 120дән артык кешенең гомере өзелгән. 51 кеше каршы як полосага чыгу тыелган урында килеп чыккан фаҗигадә үлгән. Юл һәлакәтләренең күбесе, элеккечә үк, Казан – Оренбург, Казан – Ульян трассасында күзәтелә.

Узган ел теркәлгән һәр җиде юл фаҗигасенең берсе исерек машина йөртүчеләр гаебе белән килеп чыккан. Барлыгы шундый 13 меңнән артык машина йөртүче тоткарланган. Әле безнең кулга эләкмәгәннәре дә күпме, дип тә өстәде министр. Исерек килеш рульгә утыручылар республиканың сигез районында арткан.

– Кайбер районнарда хәтта исерек килеш машина йөрткән администрация вәкилләре дә эләкте. Калганнарга ни эшләргә кала? – диде Хохорин.

Аерым алганда, Тәтеш районында инспекторлар муниципаль дәрәҗәдәге ике түрәне, Нурлатта исә моңарчы башкарма комитет җитәкчесе һәм юлда йөрү иминлеге буенча комиссия рәисе вазыйфаларын башкарган кешене тоткарлаган.

Рөстәм Миңнеханов бу мәсьәләдә беркемне дә аямаска кирәк дигән фикердә.

– Исерек килеш машина йөртүчеләргә каршы көрәшкә җәмгыятьчелекне дә җәлеп итәргә кирәк. Алар хокук бозучылар турында хәбәр итеп торсын. Исерек йөртүчеләрнең йөзләрен дә күрсәтеп торырга кирәк. Алар бит барыбыз өчен дә куркыныч тудыра. Вазыйфаи затлар турында сүз дә була алмый. Аларны бер тамчы кызганасы юк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Юллардагы вазгыятьне ничек үзгәртеп була соң? Артем Хохорин фикеренчә, моның өчен тавышлы юл сызыклары булырга тиеш. Узган ел аны кайбер юл участокларында сынап караганнар инде. «Нәтиҗәсе булды: тавышлы юл сызыгы пәйда булгач, биредә бер генә юл һәлакәте дә теркәлмәде», – ди ул. Министр гадәти буяулы юл сызыкларыннан бөтенләй баш тарту яклы.

Артем Хохорин машиналарны узу тыелган урында берничә тапкыр кагыйдә бозган машина йөртүчеләргә каралган җәзаны да катгыйлатыр чак җитте дигән фикердә. Узган ел юлларда шундый 400 машина йөртүче эләккән.

– Шуңа күрә машиналарны узу һәм тизлекне сагатенә 60 чакрымнан да арттыру кагыйдәләрен кат-кат бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында закон кабул итәр чак җиткәндер дип саныйбыз. Җәза билгеләгәндә фото һәм видеотеркәү камераларына эләккән дәлилләрне дә исәпкә алырга кирәк. Бу бик яхшы нәтиҗә бирәчәк, – дип ышандырды Хохорин.

Якын киләчәктә юл кырыендагы камералар җәяүлеләрне уздырмаган машина йөртүчеләрне дә эләктерә башлаячак. Казанда ун урында моның өчен махсус камералар урнаштырылачак. Сүз уңаеннан, узган ел Татарстан юлларында теркәлгән 950 юл фаҗигасе җәяүлеләр гаебе белән килеп чыккан. Аларның 74е үлгән. Мондый аянычлы очраклар, нигездә, җәяүлеләрнең игътибарсызлыгы аркасында килеп чыга, ди белгечләр.

– Профилактика эше тиешле дәрәҗәдә алып барылса, бу фаҗигаләрне булдырмыйча калырга да мөмкин булыр иде. Чынлыкта 18 районда моның өчен берни дә эшләнмәгән, – диде министр.

Бу урында утырышта катнашкан Рөстәм Миңнеханов түзеп кала алмады. Юллардагы иминлек мәсьәләсенә салкын караган район башлыкларын бастырып, канәгатьсезлек белдерде. Тәнкыйтьне Буа, Питрәч, Биектау районнары җитәкчеләренә иштергә туры килде.

– Бер дә матур түгел. Тәртип урнаштырыгыз. Бу эшне районнарда Хохорин белән мин килеп эшләргә тиешме әллә? Моның өчен сез бар бит! – диде Рөстәм Миңнеханов.

Юллардагы фаҗигаләр санын киметү өчен дрон кебек җиһазлар да куллана башларга кирәк, дип саный Президент. «Алар каршы якка чыгучыларны да шундук ачыкларга ярдәм итәр иде. Бездә әлегә мондый җиһаз кулланылмый. Ул Краснодарда гына бар. Безгә дә бу тәҗрибәне өйрәнергә кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТОТРЫКЛЫ ҮСЕШТӘ

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Аксубай һәм Нурлатка сәфәр кылды. Район советы сессияләрендә узган елга нәтиҗә ясап, быел нәрсә эшләргә кирәклеге турында сөйләштеләр.

Аксубайда парламент башлыгы капиталь төзекләндерүдән соң ачылган район үзәк хастаханәсендә булып, медицина хезмәткәрләре, сырхаулар белән аралашты. Хастаханә сәламәтлек саклау өлкәсенең беренчел буынын яңарту федераль программасы кысасында төзекләндерелгән. 1984 елда ук төзелгән бина моңарчы ремонт күрмәгән булган. Хастаханә бинасын төзекләндерү һәм өстәмә җиһазлауга 30 миллион сумнан артыграк акча тотылган.

Район Мәдәният йортында узган хисап сессиясендә район советының узган елдагы эшенә йомгак ясалды, быелга планнары билгеләнде. Хакимият башлыгы Камил Гыйльманов районда илкүләм проектлар һәм республика дәүләт программаларын тормышка ашыруны аерым игътибар үзәгенә алды. Узган елда Аксубай районында 60тан артыграк объект төзелгән яки төзекләндерелгән.

Ел йомгаклары буенча, районда тулаем җирле продукт күләме 16,9 миллиард сумга җиткән (алдагы чордагыга карата – 148,2%). Узган елның 11 аенда сәнәгатьтә җитештерү индексы 100,8% тәшкил иткән. Районда инде 5 предприятие резидент булган «Морозко» сәнәгать паркы үз эшен башлаган. Аксубай җитештерү-икътисадый күрсәткечләре буенча районнар рейтингында 15 нче урынга чыккан (узган елда – 21 нче урында). Ел йомгаклары буенча авыл хуҗалыгы продукциясенең тулаем күләме акчага салып исәпләгәндә, 4,4 миллиард сум тәшкил итә. «Дәүләт программалары фермерлык хәрәкәтен үстерүгә гаять зур этәргеч бирде», – диде Камил Гыйльманов.

Парламент башлыгы Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, район үсә, тулысынча файдаланылмаган мөмкинлекләр дә бар әле. Кече һәм урта бизнесны үстерүгә җитди игътибар бирергә кирәк. Тулаем җирле продукт күләмендә бизнесның өлеше республика буенча уртача күрсәткечтән (25%) кимрәк – 14–15% чамасы гына. «Районда булдыклы, актив кешеләр күп, аларның башлангычларын хуплап, бизнеска җәлеп итәргә кирәк», – дип мөрәҗәгать итте Фәрит Мөхәммәтшин авыл җирлекләре башлыкларына һәм район җитәкчелегенә. Аның әйтүенчә, Аксубайда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыру өчен дә мөмкинлекләр бар. Дәүләт Советы Рәисе районның авыл хуҗалыгы тармагындагы мөһим мәсьәләләр арасыннан сөт җитештерүнең кимүен билгеләп үтте. «Киләсе елда күрсәткечләр югарырак булыр дип уйлыйм», – диде ул.

Аксубайдан Дәүләт Советы Рәисе Нурлатка юл тотты. Район һәм шәһәр советларының берләштерелгән сессиясендә узган елгы эш йомгаклары турында район хакимияте башлыгы Алмаз Әхмәтшин сөйләде. 2022 елда тулаем җирле продукт күләме 88 миллиард сумнан артып киткән (үсеш темпы – 111,3 процент). Район икътисадында, гадәттәгечә, нефть тармагы зур өлеш алып тора. Биредә 9 нефть компаниясе теркәлгән. Узган елда алар барлыгы 5,9 миллион тонна нефть чыгарган. Шуның 2,5 миллион тоннасы чамасын – район территориясендә. Авыл хуҗалыгында җитештерү күләме 4,5 миллиард сум (үсеш темпы – 122%) тәшкил иткән. Районда 12 меңнән артыграк шәхси ярдәмче хуҗалык, 77 фермер хуҗалыгы эшләп килә.

Алмаз Әхмәтшин әйтүенчә, районның төп бурычларыннан берсе – нурлатлыларны сыйфатлы эчәр су белән тәэмин итү. «Шәһәр һәм районда яшәүчеләр 40 елдан артыграк чиста суга кытлык кичерде, – диде район хакимияте башлыгы. – Проблеманы хәл итү өчен геология-разведка эшләре башкарылды, су белән тәэмин итү системасы проекты эшләнде. Төзелешне быел ноябрь аенда төгәлләү күздә тотыла. Яңа объект Нурлатта яшәүчеләрнең барысын да сыйфатлы су белән тәэмин итәчәк».

Федераль һәм республика программалары буенча яңа социаль объектлар төзү дәвам итә. Узган елда Новое Иглайкино авылында фельдшер-акушерлык пункты ачылган. Нурлат районы үзәк хастаханәсенең йогышлы авырулар бүлеген капиталь төзекләндерү төгәлләнеп килә.

Дәүләт Советы Рәисе билгеләп үткәнчә, район социаль-икътисадый үсеш рейтингында бер ел эчендә 40 нчы урыннан 23кә күтәрелгән. «Хәзер инде темпны киметмәү мөһим, бу күрсәткеч артында Нурлатта яшәүче барча кешенең хезмәте ята, – диде ул. – Миңа калса, Нурлат районы күп кенә тармаклар буенча тотрыклы үсешне тәэмин итәрдәй җитештерүне оештыру юлын тапкан».

Фәрит Мөхәммәтшин авыл хуҗалыгы җирләреннән нәтиҗәле файдалану, мөгезле эре терлек санын киметмәү мәсьәләләренә аерым тукталды. «Нурлат районы елны уңышлы төгәлләде, районны үстерү буенча зур социаль һәм икътисадый мәсьәләләр хәл ителгән. Әмма хәл ителмәгәннәре дә бар. Аерым алганда, республика һәм федераль программаларда, грант проектларында катнашу эшен көчәйтергә кирәк», – диде ул.

Җаваплы караш

Тормышта барысы да гаилә тәрбиясенә бәйле. Гаилә – төп кыйммәт. Татарстан Дәүләт Советы һәм Идел буе федераль округы төбәкләренең хатын-кыз депутатлары стратегик сессиясе утырышында төп фикер әнә шул булды.

Хатын-кыз депутатлар «Бердәм Россия» партиясенең «Халык программасы»н тормышка ашыру буенча үз тәкъдимнәре белән уртаклашырга җыелды. Татарстан Дәүләт Советындагы хатын-кыз депутатларның «Мәрхәмәт – Милосердие» берләшмәсе җитәкчесе Алсу Нәбиева билгеләп үткәнчә, стратегик сессия эшендә федераль округның 13 төбәгеннән 400дән артык депутат катнашкан. Алардан законнар һәм башка документларга үзгәреш кертү буенча 110 тәкъдим кабул ителгән.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, хатын-кыз депутатлар, берләшеп, гаиләне, аналарны һәм балаларны яклау, социаль яклау, патриотик тәрбия бирү кебек бик актуаль мәсьәләләрне күтәрә, ә болар – җәмгыятебезнең төп кыйммәтләре.

– Сез – безнең таянычыбыз, кайчакта хатын-кыз депутатларны яхшырак та ишетәләр. Кайгырту, киләчәк буынның иминлеге, җаваплылык – болар барысы да хатын-кыз җилкәсендә. Ил һәм дөнья өчен катлаулы булган чорда сезнең эшчәнлек аеруча әһәмиятлә һәм кыйммәтлә ия, – диде ул. – Без гаиләләр таркалганга борчылабыз. Бала тулы булмаган гаиләдә яшәргә мәҗбүр кала. Иң куркынычы: хәзерге балалар смартфон, интернет дөньясы, татуировкалар ясату модасы, ЛГБТ пропагандасы басымы астында яши. Алар өчен теләсә нинди мәгълүмат ачык. Моның нәтиҗәсе аяныч булырга мөмкин. Безгә ят булган күренешләрне, дөньяга карашларны тормышыбызга кертмәс өчен, чаралар күрергә кирәк.

Хатын-кыз депутатлар алдында хәл итәсе мәсьәләләр байтак. Икенчел торак базарында торак сатып алганда ташламалы «Гаилә ипотекасы»н федераль дәрәҗәдә гамәлгә кертү, инвалид балаларны белем бирү оешмаларында ике мәртәбә түләүсез ашатуны тәэмин итү, сирәк очрый торган авырулардан препаратлар табу шулар арасында.

Ләйсән САФИНА

КАЗАННЫҢ ШАЛЯПИНЛЫ КӨННӘРЕ

«Аның исеме – безнең өчен бренд ул!» 13 февральдә танылган опера җырчысы Федор Шаляпинның тууына 150 ел тула. Бу җәһәттән җырчының туган ягында шактый чаралар узачак. Татарстан Хөкүмәте йортында узган брифингта әнә шулар турында сөйләделәр.

Федор Шаляпинның 150 еллыгын бәйрәм итүне Президент Рөстәм Миңнеханов та Указ белән раслаган. Татарстанның горурлыгы булган җырчының исемен февральдә генә түгел, ел дәвамында һәм күп тапкыр ишетәчәкбез әле.

– Федор Шаляпин – илебездәге һәм дөнья күләмендәге музыка сәнгатен үстерүгә бәяләп бетергесез өлеш керткән бөек рус җырчысы. Аның исемен һәм талантын, геосәяси вазгыятькә карап тормыйча, һәрвакыт хөрмәт белән искә алалар, – диде Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева.

Татарстанда исә бу хөрмәт төрледән-төрле чаралар рәвешен алачак. Мәдәният министры Ирада Әюпова сүзләренә караганда, алар арасында күргәзмә, музыкаль кичә, җырчының исемен мәңгеләштерү юнәлешендәге вакыйгалар да булачак.

– 13 февральдә Федор Шаляпин туган йортта (Пушкин урамы, 10 йорт) истәлек тактасы ачарга ниятлибез. Шул ук көнне җырчы исемендәге стипендиянең лауреатларын котлау тантанасы узачак, – дип санады ул аларның берничәсен.

Моннан тыш, 6 июнь – Рус теле көнендә Максим Горький бюсты янына (Горький һәм Шаляпин музее каршында урнашкан) Федор Шаляпинга бюст ачылачак. Бу урын юкка сайланмаган: әлеге ике шәхеснең якын дуслар булганы билгеле. Сүз уңаеннан, быел Максим Горькийның тууына 155 ел тула. Шул җәһәттән «ике дус музее»нда Шаляпинчыларга да, Горький иҗатын сөючеләргә дә хуш килә торган чаралар узачак.

Федор Шаляпинга багышланган чаралар арасында иң дәрәҗәлесе – аның исемендәге Халыкара опера фестиваледер, мөгаен. Быел ул 41 нче мәртәбә уздырыла һәм 30 гыйнварда «Сивильский цирюльник» спектакле белән башланды. Февраль азагына кадәр Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры сәхнәсендә тагын 9 спектакль һәм 2 гала-концерт күрсәтергә ниятлиләр. Театр директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов сүзләренчә, моңа кадәр фестиваль, нәрсә генә булса да, ел саен уздырылган.

Быелгы фестивальнең беренче спектаклен Италиядән килгән режиссер Джузеппе Морасси куйган. Ә әсәрне Рәүфәл әфәнде үзе сайлаган. «Катлаулы вазгыятькә карамастан, килеп куя алырлык режиссер да табылды», – диде ул.

Фестивальдә Россия опера сәнгатенең танылган артистлары белән беррәттән Италия, Белоруссия, Грузия һәм Әзәрбайҗаннан килгән кунаклар да чыгыш ясаячак. Ләкин кунакларга татар операсын күрсәтергә җыенмыйлар. Рәүфәл Мөхәммәтҗановның бу җәһәттән фикере башка төрлерәк:

– Без андый бурыч куймыйбыз. Әгәр күрсәтәбез, дисәк тә, кем алдында күрсәтик? Татарстан халкына үзебезнең татар операсын күрсәтикме? Ул аны болай да күрә һәм тыңлый бит.

Журналистлар белән очрашуны Ләйлә Фазлыева йомгаклады.

– Шаляпин исеме һәрвакыт Казан һәм Татарстан тарихына бәйле. Аның исеме – безнең өчен бренд, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Әйтеп кенә бактым

Ленин башы

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Элек язучылар район-авылларга ниндидер чарага йөрмәделәр. Әсәрләрен мәктәп дәреслекләре, китаплар аша гына укып белгән әдипләрнең үзләре белән очрашу халык өчен зур бәйрәмгә әйләнә иде. Бүген дә хәтерлим, «фәлән язучы, төгән язучы килә икән» дигән хәбәр таралса, авыл берничә көн алдан гөжли башлый иде. Әдипләребез хәзер дә тик ятмый. Аларның кайларга барулары, кемнәр белән очрашулары турында хәбәрләр әледән-әле чыга тора. Тик бу йөрүләр – башка төрле йөрү инде.

Элек Язучылар берлегендә пропаганда бүлеге бар иде, кайсы әдипнең кайчан, кая барасы алдан ук планлаштырылды. Акча да түләгәннәр. Бер дус язучы очрашуда катнашкан өчен 16 сум түләгәннәрен искә төшереп утырды әле. Ул заманда күп акча иде бу, 3 сумга ресторанда ашап-эчеп чыкканны үзем дә хәтерлим. Ә сәфәр вакытында булган төрле кызыклы-гыйбрәтле вакыйгалар, язучылар телендә сөйләнә-сөйләнә, буыннан-буынга күчеп килә. Еллар узган саен, яңа төсмерләргә байый. Язучы кеше бераз үзеннән дә өстәмәсә, язучы булмый бит инде ул, бераз «шыттырырга» аларга куш. Бер язучы сөйләгән вакыйганы мин дә үземчә бераз баетып язам әле.

Бер районда халык белән очрашу тәмамлангач, олпат әдибебез Нәби Дәүлигә Ленин бюстын бүләк итәләр. Бик зур булмый ул үзе, әмма таш барыбер авыр бит инде, аны авылдан-авылга күтәреп йөртәсе. Район җитәкчелеге сугыш ветераны, фашист концлагерьларында күпме җәбер-золым күргән, аннан соң берничә иптәше белән концлагерьдан качып, безнекеләргә кушылган, кулына корал тотып, Җиңү көнен якынайткан Нәби ага өчен бүләкне бик җентекләп сайлый һәм иң олы бүләк булыр дип, «Ленин башы»на туктала. Зур рәхмәтләр әйтеп ала аны әдибебез. Әмма авылдан-авылга очрашуларга йөргәндә Ленин бюсты нигәдер онытылып кала. Ярый әле район партия оешмасы уяу.

Олы бүләкнең онытылып калуы турында ишетүгә, райком вәкиле Нәби Дәүлине «куып тота» да чираттагы очрашуга җыелган халык алдында бюстны яңадан бүләк итә. Язучылар мондый хәлнең ничә тапкыр кабатлануы турында төрлечә сөйли һәм, әлбәттә инде, һәрберсе берәр очрашу өсти. «Шыттыру» шул дәрәҗәгә барып җитә ки, имеш, Нәби агага Ленин бюстын соңгы тапкыр кичке сәгать унда, Казанга кайтучы поездны куып җитеп, халык белән шыгрым тулы вагонда тапшырганнар. Бар халык кул чапкан, алкышлар чираттагы тукталышка хәтле дәвам иткән, дип сөйләүчеләр дә бар.

Әгәр «гасырлар кешесе»нә бәйле булмаса, бу мәзәккә тартым вакыйга инде күптән телдән төшеп калган булыр иде. Һәм монда Ленинны да, Нәби аганы да, шул заман җитәкчеләрен дә берничә мыскыллау юк дип уйлыйм. Алай гына да түгел, юлбашчыга хөрмәт хисләрен дә тойган кебек булам. Яратмаган кешенең исемен дә телгә аласы килми бит ул.

Бу язманы укыганда, күп кеше, бигрәк тә яшь буын вәкилләре елмаеп куяр. Мин дә елмаеп язам, әмма шул ук вакытта Ленин шәхесе бик уйландыра. Заманында Татарстан партия өлкә комитетында эшләп, шөкер, хәзер дә исән-сау бер җитәкче белән сөйләшеп утырганым бар. Ленин турында сүз чыккач, ул: «Аны тәнкыйтьләүчеләр Ленин хезмәтләре белән тулысынча таныш түгел, шуңа күрә берьяклы гына бәя бирәләр. Җитәкченең берсен дә я ак, я кара буяу белән генә сурәтләргә ярамый», – дигән иде.

Бу язмага тотыныр алдыннан Ленинның кайбер хезмәтләренә күз салдым. Мине бигрәк тә аның Россиядә, аннан СССРда милләтара мөнәсәбәтләргә кагылышлы фикерләре кызыксындырды. Әле 1914 елда ук ул милләтләрнең үзбилгеләнү хокуклары турында язып чыга. Россия халыкларының үзбилгеләнү генә түгел, хәтта аерылып чыгу хокуклары да булырга тиеш, ди. Әлбәттә, Ленин Россияне бүлгәләү, таркату турында сүз алып бармый, һәр очрак аерым каралырга тиеш, ди. Шул ук вакытта карагруһ рус шовинистларын тәнкыйтьли.

Ленинның тагын бер фикере нәкъ бүгенге вазгыятькә кагыла кебек. Барлык халыкларның яшәү рәвешен бер калыпка кертүгә каршы була ул. Әгәр исән булса, Американың бүгенге шундый сәясәтен эттән алып эткә салыр иде һәм, мөгаен, «Бер генә милләт гегемон була алмый», – дип тә өстәр иде Ленин. Аның фикерләре Украина милләтчеләренә дә кагыла.

Кыскасы, тарихны кемгә ничек кирәк, шулай язу – җәмгыять өчен иң куркыныч нәрсә дип әйтәсе килә. Җитәкчеләргә дә объектив бәя бирсәк иде. Кеше гел яхшы гына яки гел начар гына була алмый бит инде ул.

ПЬЕДЕСТАЛГА ЯЛГАН МЕНГӘНДӘ

31 гыйнварда Джо Байден Демократик партиянең милли комитеты оештырган чарада катнашты һәм климат үзгәрешләренең атом-төш коралына караганда да шомлырак булуын әйтте. Байден белән бер нәрсәдә килешергә була: атом-төш фаҗигасеннән кешелек дөньясы сакланырга мөмкин әле, әмма табигатьтәге үзгәрешләр кире кайтарып булмый торган чикне узып бара.

Соңгы елларда без даими рәвештә Гарәбстан чүленнән көчле яңгырлар һәм хәтта кар явуы турында шаккатмалы видеохәбәрләр алабыз. Зур гаҗәпләнүнең сәбәбе шул: моңарчы корылыктан интеккән һәм кысыр булган гарәп чүле еш яңгырлар нәтиҗәсендә үзгәрә, яшеллеккә күмелә бара. Андый үзгәрешләрнең кыямәт алдыннан булачагын һәм гарәпләрнең илләренә гөлбакчалар әйләнеп кайтачагын ахырзаман илчесе Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) моннан унбиш гасырга якын элек әйтеп калдырган. Бу юллар авторының дәһшәтле һәм зур фаҗигагә китергән Мәккә яңгырын үз күзләре белән күзәтеп торганы бар. Һәм чүлдән үткәндә, аның яшеллеккә күмелә баруына игътибар итеп: «Бу без киноларда күреп күнеккән чүл түгел икән инде», – дип уйлаганы да исендә.

Кыямәтнең вак билгеләре хәзер шулкадәр җыелды һәм шул дәрәҗәдә йөзгә бәреп һәм күзгә кереп тора: алар турында азмы-күпме мәгълүматы булган һәркем таң кала. Әмма минем язмам табигатьтәге үзгәрешләр хакында түгел әле. Ахырзаман билгеләренең безнең тормышның аркау һәм буй җепләренә әйләнгән һәм зур бәхетсезлекләргә китерүче берсе хакында сөйләшергә телим. Ул билге пьедесталга шулкадәр күтәрелде һәм подиумга менгән фахишә кебек шулкадәр ачык күренеп тора: аннан качу да, котылу да кыен.

Пәйгамбәрнең хәдисен китерик әле башта: «Хакыйкатьтә Дәҗҗәл чыгар алдыннан ялган вакыты җитәчәк. Дөреслекне әйтүчене ялганчы дип санарлар, ялганчыны дөресен әйтә дип исәпләрләр; хыянәтчеләргә ышанырлар, ышанычлыларны хыянәтче дип санарлар һәм шул чакта гомуми эшләр хакында сөйләүче бозыклар телгә килер». Тагын бер хәдис өстик: «Шундый көн җитәр: кешеләр бер-берсе белән сәүдә итәрләр, ләкин арада ышанырлык беркем дә калмас диярлек. Кешеләр, фәлән кавемдә ышанычка лаек бер ир бар, дип сөйләшерләр. Алар йөрәкләрендә горчица орлыгы кадәр дә иман булмаган кешеләрнең акылына, кыланмышларына һәм көченә сокланырлар». Бу хәдисләрне мин күптән түгел генә хөрмәтле һәм ышанычка лаек бер кешегә сөйләдем. Ул: «Син бит безнең көннәр турында сөйлисең, бу бит – без яшәгән вакыт», – диде.

Ялган, әлбәттә, барлык заманнарда да яшәгән. Әмма кешеләрдә аңа карата нәфрәт була, алдашучыны күралмыйлар һәм җәзага тартырга тырышалар. Кайчан кешеләр күңелендә ялганга карата иммунитет бетә, шунда ул пьедесталга күтәрелә дә инде.

2010 елда бу юлларның авторы зур бер җыелышта утырды. «Укытучы елы» дип игълан ителгән иде ул. Шуңа күрә ул җыелышта укытучыларны хөрмәтләделәр. Районнан чыккан зур шәхесләр үзләрен укыткан укытучыларга бүләкләр тапшырды, чыгыш ясадылар. Сүз уңаеннан әйтик: безнең җәмгыятьтә укытучы кадәр конформистны, ягъни урнашкан тәртипләр белән пассив рәвештә килешеп, яраклашып, өстенлек алган фикергә буйсынып яшәүче башка профессия вәкилләрен табу кыен. Озак еллар буе мәктәптә эшләгән укытучы булараК мин шулай дип уйлый идем. Әмма бер аналитик берничә көн элек кенә: «Хәрбиләр укытучыга караганда да конформистрак», – дип әйтеп, фикеремне бераз үзгәртте. Остазлары конформист булгач, чир җәмгыятьнең барлык әгъзаларына да тарала инде, бу гаҗәп түгел.

Сүз теге җыелыш турында иде бит әле. Шунда җәмгыятьтә тоткан урыны белән барыбыздан да өстен булган, югары хөрмәткә ия бер шәхес чыгыш ясады һәм тормышның бик күп тармакларына җитәкчелек иткән кеше буларак ике фикер әйтте. «Җитәкче ялганламыйча идарә итә алмый», – диде ул. Мин андый белдерүдән соң зал тын калыр һәм нәфрәт белән гүелдәр дип көткән идем, әмма берникем дә пауза булмады, зал бердәм һәм көчле алкышларга күмелде. Икенче фикерне мин бераз оныта төшкәнмен. Аны ялган турындагы хәдисләрне әйткәч таң калган әңгәмәдәшем исемә төшерде. Анысы болайрак яңгырый: «Җитәкче урлашмыйча яши алмый, чамасын белеп урлашырга кирәк». Алкышлар тагын да көчлерәк иде. Җыелыштан авыр тойгылар белән чыгып китәргә туры килде. Җитмәсә, теге шәхес, үзенең сыйныф җитәкчесен бүләкләгәндә, күңеле нечкәргән остаз сәхнәдән төшеп китә алмыйча фикер әйтергә дип микрофонга үрелгәч, укытучысын бар кеше алдында бик ямьсез итеп этеп җибәрде һәм аның колагына нидер пышылдады.

vk.com

Безнең җәмгыятьнең хәзерге хәле шундый. Сүз Россия турында гына бара дип уйламагыз тагын, ялган глобаль рәвештә планетаның барлык төбәкләрендә дә хакимлек итә. Хәтта нурлы Мәдинәдә йөргәндә дә бик сак булырга кирәк. Төп башына утыртырга теләүчеләр анда да табылачак. Әйе, кайчандыр кешеләре иманы-дине алдашудан тыя иде, ул булмаса, җәмгыятьтәге законнар җәзасыннан куркып тыелалар иде. Бу чикләр күптән юылды инде. Бик ышанычлы дип санаган кешегә зур суммада акча биреп торып кулы пешкән кеше буларак язам моны.

Без яшәгән чорның фаҗигасе шунда: кешеләр ялганны яраталар һәм (гаҗәп инде) чын дип кабул итәләр. Бу мошенникларга алар белән бармак тирәсендә әйләндереп йөрткән кебек идарә итәргә мөмкинлек бирә. Телефон мошенниклыгының киң таралуы – шуның нәтиҗәсе. Әллә ничә мең километр ераклыкта утыручы алдакчылар (төрмә камерасында да булырга мөмкин алар) телефоннан шундый итеп алдыйлар: гипнозланган кешеләр (арада зур банклар җитәкчеләре бар) үз хисапларында акча җитмәгәч, миллионлы кредитлар алып, караклар хисабына җиңел генә күчерәләр. Эш шундый киң масштаб алды: хәзер, ялган белән гипнозламасыннар өчен, «Госуслуги» аша үзеңә үзең кредит алуны тыюны рәсмиләштереп була. Шулай эшләсәң, мошенниклар гипнозлаганда, кредит алып, аларны баетырга телисең, әмма алдан рәсмиләштерелгән тыю булгач, банк сиңа кредит бирми. Малың бөтен кала. Ялганны яратасың һәм ялганда тәрбияләнгәнсең икән, үз-үзеңә дә ышанырга ярамый, яратканың белән җәзаланасың, дигән сүз бу.

Ялган җәмгыятькә бик зур матди һәм рухи зыян сала, тормышны фаҗигагә әверелдерә. Дәүләт оешмалары тирәсендә урнашкан бизнес, бернинди уңай нәтиҗәләргә китермәсен белә торып, бик зур проектларга акчалар ала. Түрәләр дә беләләр: бу проект уңышсыз булачак, үз-үзен акламаячак, әмма акчаны мул бүләләр. Үзкыйммәт берничә тапкыр арттырып күрсәтелә, акча бюджеттан булгач, үзем тапкан мал түгел дип, беркем дә борчылмый. Теге укытучыларны бүләкләгәндә зур шәхес әйткән чикләр (чамасын белеп урлау) онытыла. Бик күп акча суга салына, җиргә күмелә. Мәгариф, фән, сәламәтлек саклау тармакларына финанслар калмый. Системаны тоту өчен, бюджетны силовиклар файдасына бүләргә туры килә.

Акка кара белән тегелгән сылтаулар табып, зур конфликтлар оеша, кешелек җәмгыяте дөньякүләм бәрелешкә якыная. Иммунитетын югалткан массалар үз фаҗигаләренә таба берни дә аңламыйча атлыйлар. Югарыда Байден әйткән климат үзгәрешләре куркынычрактырмы әле монда, җәмгыятьтә үлчәүнең ялган тәлинкәсе басу һәлакәтлерәктерме?

Күптән түгел генә бер автор, демократик җәмгыятьтә ахмаклар хакимияткә килә алмый, дигән фикер әйтте. Пәйгамбәрнең (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) ялган турындагы хәдисе кире кага аның демократия белән алдануын. Кыямәт алдыннан бөтен халык эшләрен ахмакларның үз кулларына алачагын әйтә Аллаһның илчесе ул хәдистә. Без шуны күрмибезмени, аек акылга сыймый торган хәлләр тормышыбызга планетакүләм фаҗига буларак бәреп кермиләрмени?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

НИГЕЗ КАДЕРЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Тияргә ярамый тотарга

Россиядә, шул исәптән Татарстанда, иясез йортларның һәм җирләрнең бердәм саны алып барылмый. Шулай да иясез йорт учетка куелган очракта, күбрәк мәгълүматны кучемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмә соратып белеп була. Сүз уңаеннан, Росреестрның Татарстан идарәсеннән алынган мәгълүматлар буенча, 2022 елда бердәм дәүләт реестрында мәгълүматлары булган 4,5 млн күчемсез милекнең 700 меңнән күбрәгенең хокукы теркәлмәгән. Шуларның 112 меңе – торак йортлар, 326,5 меңе – җир кишәрлекләре.

Ташландык йортлар проблемасы кукмаралыларны да борчый. Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы Марат Зәйнетдинов әйтүенчә, әлеге мәсьәләне халык авыл җыенында да күтәреп чыккан. Җирлеккә дүрт авыл керә. 276 хуҗалыкта 830 кеше яши. Узган ел дүрт авылда өч бала туган, 17 кеше дөнья куйган.

– Ташландык хәлдәге йортлар халыкны борчыган сорауларның берсе инде. Ут-күз куркыныч бит. Теләсә нинди хайваннар да ияләшергә мөмкин. Авылның да ямен ала алар. Шуңа күрә авыл халкы моңа битараф була алмый, – диде ул.

Авылны ямьсезләп торсалар да, җирлек башлыклары барлык «бюрократия баскычлары»н узмыйча, иске йортларны сүтеп, җимереп атарга хокуклы түгел. Закон нигезендә, милек белән идарә итү, аны файдалану – милекче карамагында. Шул рәвешле, йортның хуҗалары гына торакларын сатарга, бүләк итәргә хокуклы.

Шул ук вакытта күчемсез милек, төзелеш объектлары, җир кишәрлекләре хуҗасыз дип тә танылырга мөмкин. Закон буенча, йорт хуҗасының варислары булмаган яки алар милектән баш тарткан, яки үз вакытында милек хокукын алмаган очракта, суд карары нигезендә йорт муниципалитетка күчә. Йортны хуҗасыз дип тану иң катлаулысы да инде. Иң элек ул хуҗаны эзләп табасы бар бит әле. Бәлки милек иясе авылда мирас буенча йорт күчкәнен үзе дә белми торгандыр? Яки күптәннән чит илдә яши, һәм гомерендә дә әлеге авылга аяк атлаганы юктыр?

Марат Зәйнетдинов әйтүенчә, 2021–2022 елларда шундый өч йортны сүткәннәр. Калганнары, ияләрен таба алмау сәбәпле, үз урыннарында утыра бирә.

– Ул йортларны иясез дип тә әйтеп булмый. Кайчандыр шушы нигездә гомер иткән апа-абыйларның балалары башка җирдә яшиләр. Ә мирасны теркәтергә теләмиләр, кайтып та йөрмиләр, – диде ул. – Бөтенләй читкә чыгып киткәннәрен эзләп табып булмый. Якын-тирәдә булганнарын табып, ничек тә рәсмиләштерергә тырышабыз. Ә инде бөтенләй кирәксенмиләр икән, вариссыз милек (выморочное имущество) буларак теркәп, ул суд аша җирлеккә күчә. Әйтик, авылыбызда өйләнмәгән, туган-тумачасы, ягъни варисы булмаган бер ялгыз кеше үлеп китте. Бер елдан соң аның йорты суд аша җирлек карамагына күчәчәк. Киләчәктә әлеге участокны, йорт салыр өчен, башка кешегә бирә алачакбыз. Әлеге көндә җирлектә балалары рәсмиләштермәгән иясез биш йорт бар.

Хәер, авылларда күпчелек ташландык йортларның хуҗалары кем икәнлекләрен чамалыйлар да.

– Берничә йортны ана капиталын файдаланып рәсмиләштерә башлаганнар иде. Тик эшләре ярты юлда тукталып калды. Кайтмыйлар да, яшәмиләр дә. Берсе Оренбург якларында тора ди бугай, белдерү кәгазе җибәрү өчен бездә аның төгәл адресы да юк. Бик иске йорт ул. Берни дә эшләтә алмыйбыз, сүтеп атарга да хокукыбыз юк, – ди Марат Зәйнетдинов.

Хуҗасыз йортлар Әтнә районының Түбән Бәрәскә авылында да бар. Җирлек башлыгы Аида Фатыйхова фикеренчә, бу мәсьәләдә законга үзгәрешләр кертү кирәк.

– Ташландык йортларны хуҗасыннан җирле үзидарә карамагына җайлы гына күчерергә мөмкинлек биргән закон кабул ителсә, яхшы булыр иде дә. Мәсәлән, кеше берничә ел дәвамында кайтып нигезен рәткә китерми яки рәсмиләштерми икән, аның торагы автомат рәвештә дәүләткә күчә торган булса, безгә эшләү күпкә җайлырак булыр иде. Бәлки кеше үз нигезенең кадерен белер, кайтып карар иде. Авыл да матуррак, чистарак булыр иде. Ташландык йортларны сүтеп, күпбалалы гаиләләргә, йорт салырга теләүчеләргә дә бирергә мөмкинлек чыгар иде, – диде ул.

Күпчелек авылларның баш авыртуы булып торган мәсьәлә Мамадыш районының Яке авылына бөтенләй хас түгел диярлек. Авыл халкы: «Бездә андый йортлар гомумән юк», – дигәч, җирлек башлыгы Рафаил Низаметдиновка шалтыраттык.

– Чыннан да, алар бездә юк дәрәҗәсендә. Хуҗаларын таба алмаган 3–4 йорт кына бар. Аларны сораучылар да бар, тик без аны сата алмыйбыз, – диде ул. – Авылда ел дәвамында яшәмәсәләр дә, җәен кайтып, нигезне карап торучы хуҗаларның балалары шактый. Соңгы елларда кышын кайтучылар да артты. Иске йортларны алмасалар да, буш җирләргә шәһәрдән кайтып, яңа йортлар тергезүчеләр бар.

Авыл йөзе

Авыл халкын, бер яктан, кайчандыр тормыш гөрләгән, тәрәзәдән утлары балкыган, бала-чага чыр-чуы ишетелеп торган йортларның җиргә сеңеп, кадерсез булып утыруы борчыса, икенче яктан, авыл рухы һәм йөзе үзгәрүе тынгылык бирми.

Зәй районының Аксар авылында ташландык йортлар булмаса да, җирлеккә кергән башка авылларда алар шактый икән. Җирлек башлыгы Юрий Гыйльмановны мирас булып калган йортларның теләсә кем кулына күчүе дә хафага сала.

– Безнең сату-алу эшләренә бер катнашыбыз да юк. Прописката кем кергәнен, тешкәнен белми дә калабыз. Менә анысы бераз кыенлык тудыра, – диде ул. – Әйтик, җирлектәге белдерү куеп сатылган йортларга якынча 5 елда 15–20 гаилә кайтты. Шушы вакыт эчендә төрле милләт вәкилләре дә кайтып төпләнде. Сер түгел, алар арасында төрле гаиләләр бар. Авыл кабул итмәгән, имин булмаганнары да юк түгел. Шул ук вакытта яхшы, тырышлары да бар. Бүре-Сарай авылы зур түгел, күпчелек өлкәннәр яши. Йорт хуҗалары мәрхүм булганнан соң, оныклары йортларны сатты. Аларга берничә яшь гаилә кайтты. Матур гына яши киттеләр. Шулай ук ерак илләрдән йомән гаиләсе күченеп кайткан иде. Тел белмиләр, яшәү рәвешләре, гореф-гадәтләре башка. Балалары тел белмәү сәбәпле, мәктәптә укый алмады. Үзләренә дә, безгә дә бик кыен булды. Бер ел яшәгәч, тагын башка районга күченделәр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Фикер

Азат ФАЗЛЫЕВ, җырчы:

– Минем өчен нигез – беркайчан да онытылмый һәм һәрвакыт үзенә тартып торучы кадерле һәм изге урын. Анда кайткач, әти-әниле бәхетле чаклар, бала вакытлар искә төшә. Әти-әни үстергән, аларның хезмәте кергән байлык ул. Үзем исән вакытта төп йортыбыз сатылмаячак. Бу турыда хәтта сүз дә булуы мөмкин түгел. Без – өч туган, барыбыз да бер фикердә. Ул киләчәктә дә әти-әниебезнең йөзе булып саклана, безне бергә җыя торган кадерле урын булачак.

Хәзерге вакытта әти белән әнинең йорты үзләре исән чагында нинди иде, шул килеш тора. Йорт җылытыла, барлык коммуникация эшли. Үзебез кайта алмаганда, авылдагы туганнарыбыз – Гомәр һәм Фаил абыйлар, Наилә апа күз-колак булып тора. Аларга моның өчен зур рәхмәт. Әти-әни үзләре булмаса да, шөкер, нигез яши. Шунысы кызганыч: балаларыбыз гына әби-бабайлары янында җәйге каникулларын элеккечә уздыра алмаячак...

Юрий Гыйльманов фикеренчә, авылларга чит кешеләр килгәнче, шушы җирлектә туып-үскән балалар кире үз нигезләренә әйләнеп кайтса, күпкә яхшырак булыр иде.

– Кызганыч, ата-баба рухын, нигезне саклау җитми. Оныкларны матди байлык күбрәк кызыктыра. Авылга кайтып төпләнмиләр инде алар, чөнки эш юк. Бабай бакчасында шулай ук эшләргә теләмиләр, – дип көрсенде ул.

Аның фикерен Марат Зәйнетдинов та куәтләде. Аның сүзләренчә, мирас булып күчкән йортны теләсә кемгә сатып җибәрү – тагын да куркынычрак.

– Бөтенләй белмәгән кешеләр бит алар. Мәсәлән, безнең чип-чиста татар авылына башка милләт кешесе килеп урнашса, үзенә дә, халыкка да авыр. Мин аларны начар димим. Әйтик, бездә бер йортны әрмән хатыны алды. Холык-фигыле әйбәт аның, шунда ук пропискага да керде, 1960 нчы елларда салынган йортны караштыргалап, верандасын да ясатып куйды. Тик тел белмәгәч, үзенә читен. Тагын бер хатын бер ай авылда яши дә бер ай поездда озатып йөрүче булып эшли. Үзе Краснодар өлкәсеннән. «Стелла, син үзең дә бик матур урында яшәгәнсең. Монда нинди җилләр ташлады?» – дип сораганым бар аңардан. «Миңа сезнең яклар ошый, монда яшисе килә», – дип җавап биргән иде. Андыйлар да бар.

Язмамны Юрий Гыйльмановның сүзләре белән тәмамлыйсым килде.

– Мин үзем дә тумышым белән бу яклардан түгел бит. Сабадан мин, – диде ул. – Милициядә хезмәт юлымны башлаганда Зәй районына җибәрделәр. Булачак хатыным белән очрашып, гаилә корып җибәргәч, шушы якларда калдык. Ләкин ел саен туган авылга, нигезгә кайтам. Гәрчә анда башкалар яшәсә дә. Яшь вакытта бер дустым бик сорагач, йортны саткан идем. Ул башкага сатты. Хәзер әти-әни нигезендә алар яши. Барыбер кереп чыгам мин аларга. Кертмәсәләр дә, берни эшләп булмый... Урам тыкрыкларын урыйм, чөнки суга йөрдем, терлекләр кудым мин анда. Барысы да кадерле, барысы да үз миңа. Балаларыма да кайтып күрсәттем. «Шушында әби-бабагыз яшәде, мин үстем», – дип сөйләдем. Тик әгәр ул сатылмаган булса, үз йортым, үз бакчам, дип әйтер идем. Җәй көне ешрак кайтып йөрер идем. Күрәсезме, күпме гомерем Зәй якларында узса да, иле дә «Сабага кайтам» дип сөйләшәм. Чөнки минем анда төп нигезем бар...

Зөһрә САДЫЙКОВА

Газетаның «ВК» сәхифәсендә укучыларыбыз арасында «Авылыгызда ташландык йортлар бармы?» дигән сораштыру уздырдык. Анда 3376 кеше тавыш биргән. Нәтиҗәләр түбәндәгечә:

- әйе, алар бездә бик күп......65,18%
- берәү дә юк......8,63%
- бер-ике бар бугай......26,19%

ЫШАНМА КҮЗЕҢӘ!

ХАЛЫК НИ ӨЧЕН БАЗАРДАН ИНТЕРНЕТКА КҮЧТЕ?

shutterstock.com

Сатучы түгел – селлер, базар түгел – маркетплейс. Баштарак ят тоелган бу сүзләргә хәзер индеияләшеп тә барабыз. Илдә онлайн кибетләргә «йөрүчеләр» саны артканнан-арта. Былтыр интернетта бер ярым тапкыр күбрәк акча туздыргансыз әнә. Татарстанда гына да маркетплейсларда 50 миллиард сумлык товар сатылган. Онлайн сату-алулар нәрсәсе белән кызыктыра? Интернет баетамы, әллә бөлдерәме? Бу сорауга «ВТ» хәбәрчесе җавап эзләде.

Пандемиядән башланды

Сүз башы бит Шүрәле, дигәндәй, сүзне еракка җибәрмичә, иң элек «маркетплейс» сүзенә ачыклык кертик. Ул «сәүдә мәйданы» дип тәрҗемә ителә. Шул ук базар, кыскасы. Тик интернетта гына. Биредә нәкъ базардагы кебек: бер якта – кием-салым рәтләре, икенче якта – азык-төлек, өченчесендә чәйнек, кул сәгате ише көнкүреш җиһазлары белән сату итәләр. Сатучыларның очы-кырые юк. Кесә телефонындагы маркетплейсларның берәрсенә керәсең дә, әбүген интернет сәүдә мәйданчыклары арасында сайлау мөмкинлеге шактый, үзеңә кирәк булган бөтен нәрсәне берьюлы сатып аласың. Аяк талдырып йөрисе дә юк. Кирәкле күлмәк-чалбарлар махсус товар тапшыру үзәкләренә килә. Шуннан барып аласы гына кала. Маркетплейсларны интернет-кибетләр белән бутамаска да киңәш итәләр. Соңгысы бер хуҗага карый, анда товар төрләре азрак һәм ишеген ачып керерлек кибетләре бар.

– Хәзер кибеткә йөрү өчен диваннан торасы да юк, маркетплейсларны бигрәк тә шуның өчен яратам, – ди Чаллыда банк хезмәткәре булып эшләүче Лилия Насыйрова. – Соңгы тапкыр кибеткә кайчан барганымны хәтерләмим дә, ипи-тоздан алып йорт җиһазларына кадәр, барысын да интернеттан заказ бирәм. Коронавирус аркасында өйдә утырганда «дөнья пәрәвезе»нә кереп чумган идем, шуннан бирле чыккан юк. Интернет сәүдәнең отышлы яклары шактый. Кибет белән чагыштырганда, товарлар очсызрак, сайлау мөмкинлеге күп.

Авылда да ят түгел

Илдә иseme танылган банкларның берсе үткәргән тикшерүдән күренгәнчә, былтыр россиялеләр маркетплейсларда бер ярым тапкыр күбрәк акча туздырган. Халыкның барлык чыгымнарының 8,5 проценты нәкъ менә интернет сәүдә мәйданчыкларына туры килә. Белгечләр әйтүенчә, моңа, иң беренче чиратта, чит ил брендларының ил базарыннан китүе сәбәпче. Кибеттән алып булмагач, кәттә кием-салымны интернеттан эзлиләр. Икенчедән, товар төрлелеге кызыктыра. Өченчедән исә кесәдәге кибет күпкә уңайлырак. Интернет-сәүдә компанияләре ассоциациясе китергән саннарга ышансаң, былтыр «дөнья пәрәвезе»ндә 5 триллион сумлык товар сатылган. Шуның яртысы диярлек маркетплейсларга туры килгән.

Хәзер мондый заманча кибетләр авыл җирендә дә ят түгел.

– Былтыр бездә бер-бер артлы ике маркетплейсның товар тапшыру үзәге ачылды, – ди Яшел Үзән районының Норлат авылында яшәүче укучыбыз. – Интернеттагы товарларга элек тә кызыга идек. Тик күлмәк-чалбарга заказ биргән саен Казанга чыгып чапмыйсың бит. Норлат – Казан арасы бер сәгать ярымлык юл. Хәзер исә бик уңайлы. Товар 4–5 көндә авылга кадәр килеп җитә. Интернетта бәяләр очсызрак. Ә авыл кешесенең артык акчасы юк.

Халык күбрәк үз иткән маркетплейслар да билгеле. Беренче урында – «Вайлдберриз». Әлеге сәүдә мәйданчыгында былтыр 2 миллиард сумлык товар сатып алганнар. Икенче урында – «Озон». Беренче өчлеккә «Яндекс Маркет» та эләккән. Сүз уңаеннан, узган атнада Яшел Үзән районында «Озон»ның өченче өлешен төзи башладылар. Беренчесенең складларында 9,8 млн товар саклана. Биредә көненә 350 мең товарны иясенә озата алалар. Җәйгә кадәр икенче өлешен дә ачарга ниятлиләр.

Ир-атлар да ярата

– Базарда сатып алучылар кимегәннән-кими, – ди ун елдан артык башкаланың Вьетнам базарында ирләр киемнәре сатучы Гөлфидә Хуҗина. – Товарны Төркиядән кайтарам. Элек берьюлы унар капчык кием-салымга заказ бирсәм, хәзер сезонына карап, дүрт-биш капчык та көчкә сатыла. Халык интернетка күчте. Эчке киемнән алып кышкы пәлтәгә кадәр шуннан гына сатып алалар бит. Анда очсызрак, диләр. Интернет сатучыларга безнең кебек аренда бәясе, сатучыларга хезмәт хакы түлисе юк шул.

Маркетплейсларга, барыннан да бигрәк, кием-салым, аяк киеме һәм муенса, беләзек, күзлек ише аксессуарлар эзләп керәләр. «Анкетолог» иҗтимагый-фикер институты үткәргән сораштыру барышында респондентларның 59 проценты әнә шулай дигән. Икенче урында – косметика һәм парфюмерия (46 процент). Интернетта көнкүреш химиясенә һәм медицина товарларына да сорау зур икән, әлеге товарларның һәркайсы 36 процент табыш җыйган. Беренче бишлеккә азык-төлек тә эләккән.

Чыгымнарга килгәндә, ил халкының 37 проценты бер кергәндә маркетплейста уртача 1 мең 500 – 2 мең 500 сум акча туздыра, өчтән бере – 1 мең сумнан азрак, ә чирек өлеше исә 2 мең 500дән дә күбрәк акча тота. Хатын-кызлар белән чагыштырганда, интернет кибетләрдә ир-атлар күпкә юмартрак икән.

– Ә мин ике елдан бирле маркетплейста акча эшлим, – ди селлер һөнәрен үзләштергән Марат Гатауллин. – Интернетта саткан иң беренче товарым – автомобиль юу өчен хуш исле тастымал. Аны Кытайдан ун мең сумга күпләп кайтарттым. Товар өч ай дигәндә сатылып бетте, 40 мең сум керем алдым. Аннары шул акчаны машинага запас частьлар кайтартуга тоттым. Аларны да интернетта саттым. Хәзер маркетплейста дүрт төрле товар тәкъдим итәм. Былтыр 200 мең сум чиста табыш алдым. Интернетта товар сату бик җиңел дип уйламагыз. Һәр базарның үз кануннары бар. Мәсәлән, гел ташламалар ясауны таләп итәләр. Мондый акцияләрдә катнашу безгә отышсыз. Аның каравы сатып алучыларга яхшы. Шуңа күрә сатучылар еш кына бәяләрне махсус күтәрә дә аннары, ташлама дип, кире үз хакына төшерә генә. Интернетта товар сатарга теләүчеләр саны да яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр кебек артканнан-арта. Көндәшлек көчле.

Арзаннан – ялганга

Икътисад белгече Илдус Сафиуллин сүзләренә караганда, халыкның күпләп маркетплейсларга күчүенә әллә ни сөенергә кирәкми.

– Узган ел ахырында билгеле булган рәсми саннарга караганда, илдә яшәүчеләр арзанлырак азык-төлек сатып ала башлаган. Ипи-тозга да акча җитми икән, башкасы турында әйтеп тору артык. Халыкның керем дәрәҗәсе кимеде. Маркетплейсларга күчүне дә чыгымнарны киметергә тырышудан күрәм мин. Тик кемнең генә ыспай киенеп, зур сәүдә үзәкләрендәге затлы кибетләрне бер әйләнеп кайтасы килми икән? Кем әйтмешли, юрганыңа карап аягыңны сузарга туры килә, – ди ул.

Белгеч фикерен халык арасында үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләре дә раслый. Иҗтимагый фикер фонды илдә яшәүчеләрнең матди хәлен белешкән. Баксаң, күпчелек финанс кыенлыкларын азмы-күпме җиңеләйтү өчен арзанлырак товарлар сатып алуга күчкән икән. Илдә яшәүче һәр биш кешенең берсе диярлек: «Төрле кибетләрдә товар бәяләрен чагыштырам, ташламалар, акцияләр башланганны көтәм», – дигән.

Ул арада онлайн кибетләргә «йөрүчеләр» маркетплейсларда сыйфатсыз һәм шикле товарлар күбәеп китүдән зарлана башлаган. Роспотребнадзор каршындагы Иҗтимагый совет җитәкчесе урынбасары Олег Павлов әйтүенчә, еш кына брендлы кием-салым урынына «идән асты»нда тегелгәнен саталар. Мондый очраклар «Вайлдберриз»да күбрәк, дип тә өстәгән җитәкче урынбасары. Дөрес, соңгылары моның белән килешми. Ничек кенә булмасын, тиздән маркетплейслардагы товарның сыйфаты яхшырачак, дип ышандыралар. 1 марттан интернеттагы товар өчен сәүдә мәйданнары хуҗалары җавап тота башлаячак. Әлегә моның өчен сатучылар үзләре җаваплы.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Белеп тор!

Роспотребнадзор белгечләре маркетплейстан товар сатып алганда түбәндәге кагыйдәләрне истә тотарга киңәш итә.

➤Интернетта «параллель импорт», ягъни илгә арадашчылар аша кертелгән чит ил товарларын сатучылар күп. Бу очракта җитештерүчедән рөхсәт таләп ителми. Исегезгә төшерәбез: ил Хөкүмәте «параллель импорт»ны узган елның мартында рөхсәт итте һәм ул бу ел азагына кадәр дәвам итәчәк. Читтән кайткан товарлар сатып алганда аларның тышкы кыяфәтенә һәм куллану вакытына игътибар итәргә кирәк.

➤Кулланучылар онлайн акцияләр вакытында сатып алган әйберләрне аны кулга алган көннән ике атна эчендә кире кайтарып бирергә хокуклы. Шунысын да истә тотыгыз: арзан бәядән контрафакт товар сатулары да бар. Шик туган очракта, сатып алучы күлмәк яки чалбарның сыйфатын раслаучы документларны күрсәтүне таләп итә ала.

➤Сатучылар белән фәкать интернет сәүдә мәйданнарында гына аралашасы.

Узган елда Татарстан интернет сәүдәне үстерү буенча Идел буе федераль округында беренче урынга чыккан. Интернет кибетләрдә республика сәүдәгәрләренең сату әйләнеше ике тапкыр арткан. Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча Татарстан Президенты каршындагы вәкаләтле вәкил, Президент ярдәмчесе Фәрит Габделганиев әйтүенчә, мондый сату әйләнеше бездә 50 миллиард сумга җиткән. Маркетплейсларда сатучылар саны да ике тапкыр диярлек ишәйгән: 2022 елның 1 гыйнварына 23 мең булса, быел 1 гыйнварга аларның саны 45 меңнән артып киткән. Узган атнада Премьер-министр Алексей Песошин республикада 2023–2025 елларга интернет сәүдәне үстерүнең яңа программасын раслады. Фәрит Габделганиев әйтүенчә, әлеге программа Татарстанның бу базарда көндәшлеген арттырачак, тагын да күбрәк эшмәкәрне җәлеп итәргә һәм кирәкле товарларны халыкка тизрәк илтеп җиткерергә булышачак.

10 февральдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Сәрия МИФТАХОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Пенсия түлиләрме?

Ел башында Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча пенсионерларга 10 мең сум өстәмә акча түлиләр икән, дигән хәбәрләр таралган иде. Бу сүз дөреслеккә туры килмәде, ахры. Көттек-көттек, акча юк. Өстәмә пенсия булачакмы?

Фәһим СОЛТАНОВ. Арча

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге:
– Пенсия һәм социаль түләүләргә бәйле ялган хәбәрләр гел чыгып тора. Кем әйтмешли, пенсия темасы «картаймый». Без мондый имеш-мимешләргә үз вакытында аңлатма бирергә, дөреслекне җиткерергә тырышабыз. Бу – чираттагы ялган хәбәр. Хәтерләсәгез, Яңа ел алдыннан пенсионерларга униченче пенсия түләячәкләр, дип тә халыкның башын бутарга тырыштылар. Ел да бер үк хәл. Шуңа күрә өлкән яшьтәгеләргә дә рәсми, тикшерелгән мәгълүмат чыганакларыннан файдаланырга өйрәнергә кирәк. Мәсәлән, яңартылган sfr.gov.ru рәсми сайты – шундыйларның берсе.

Бурычын кайтарырмы?

Хезмәттәшем бер ел элек бурычка зур суммада акча алып торган иде. Бурычны бер елда кайтарып бирергә вәгъдә итеп, расписка кәгазе дә язды. Бу көннән инде ике елга якын вакыт узды, тик акчасы да, үзе дә күренми. Расписка кәгазендә танышымның исем-фамилиясе һәм саннар белән бурыч күләме генә күрсәтелгән. Паспорт мәгълүматлары да, акчаны кайчан кире кайтарырга тиешлеге дә язылмаган. Мондый кәгазь судта юридик көчкә ияме?

ФӘРИТ Г. Әлмәт

Марат Фәйзрахманов, юрист:
– Гамәлдәге канун нигезендә расписка заем килешүе булып санала. Ике як та үз ризалыгы белән әлеге документны төзегән икән, димәк, ул юридик көчкә ия. Бурыч күләмен сүзләр белән язу мәҗбүри түгел. Акчаны кире кайтарып бирүнең төгәл вакыты күрсәтелмәсә, ул заем алучыга бурычны кайтару турында таләп куйган көннән алып 30 көн дип санала. Шунысы бар: расписка кәгазе төзегән кешене башка документлар ярдәмендә шәрехләп бирергә туры киләчәк. Бу очракта кесә телефонындагы смс-хәбәрләр дә дәлил була ала.

Гаражны нишләтергә?

«Гараж амнистиясе» буенча Казандагы гараж һәм җир кишәрлеген бушлай рәсмиләштерергә телим. Ул закон гамәлдәме әле? Корылманың техник паспортыннан башка бернинди документларым да юк. Миңа эшне нәрсәдән башларга?

Розалия БАКИРОВА, пенсионер

Росреестрның Татарстан буенча идарәсе:
– Иң элек милекне «гараж амнистиясе» буенча рәсмиләштереп буламы-юкмы икәнен аңларга кирәк. Ягъни гараж 2004 елның 30 декабренә кадәр төзелгән булырга, капиталь корылма дип саналырга тиеш. Тагын шунысы да мөһим: ул суд яки җирле хакимият органы тарафыннан рөхсәтсез төзелгән корылма дип табылган булырга тиеш түгел. Җир кишәрлеге моңарчы рәсмиләштерелмәгән булса, ул урнашкан район башкарма комитетыннан рөхсәт документлары алырга туры киләчәк. Аның нигезендә җирне кадастр исәбенә куячаклар. Шуннан соң гына гараж һәм җир кишәрлегенә бәйле документларны, рәсмиләштерү өчен, башкарма хакимияткә тапшырырга мөмкин. Сезнең милеккә карата уңай карар кабул ителсә, аны рәсмиләштерү өчен дәүләт пошлинасы түләргә кирәкми.

Әлеге закон 2021 елның 1 сентябрендә гамәлгә керде. Ул вакыттан бирле республикада 2 мең 943 җир кишәрлеген һәм 3 мең 256 гараж рәсмиләштергәннәр. Татарстан – әлеге күрсәткеч буенча Идел буе федераль округында беренче урында. «Гараж амнистиясе»ннән файдаланучылар Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә, Әлмәт һәм Чистай районнарында күбрәк. Закон 2026 елның 1 сентябренә кадәр гамәлдә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Стаж сатыламы?

Киләсе елда пенсиягә чыгу яшенә җитәм. Тик хәзер бу гына аз, лаеклы ялга чыгу өчен иминият стажы һәм пенсия баллары да кирәк, диләр. Мин озак еллар авылда инвалид әти-әниемне карадым, рәсми рәвештә эшкә урнашмыйча, «шабашка»да йөрдем. Эштән качып йөргән кеше түгел мин, пенсиягә чыга алмыйча калсам, хурлык бит. Ул стажны сатып алырга мөмкин икән, дип сөйлиләр. Шуны аңлатып бирә алмассызмы?

Исемемне язмагыз.

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге:
– 2023 елда картлык буенча иминият пенсиясен алу өчен минималь стаж 14 ел тәшкил итә. Мәсәлән, пенсиягә чыгу яшенә җиткән кешенең 13 ел стажы бар һәм ул эшләми, ди. Бу очракта лаеклы ялга чыгу өчен җитмәгән эш елларын сатып алырга була. Мондый мөмкинлектән эшләмәүчеләр генә түгел, рәсми рәвештә теркәлгән үзмәшгульләр дә файдалана ала. Моның өчен еллык керемнәрне түләргә кирәк. Ә иминият елы ХТМК × 22% × 12 формуласы буенча исәпләнә. Быел ХТМК, ягъни хезмәт өчен түләүнең минималь күләме 16 мең 242 сум тәшкил итүен исәпкә алсак, бер ел стажны 42 мең 878 сумга сатып алырга мөмкин. Канун нигезендә, иминият пенсиясе билгеләү өчен кирәкле стажның яртысы кадәрен: 2023 елда – күп дигәндә 7 елны, 2024 елда – күп дигәндә 7 ел да 6 айны, ягъни лаеклы ялга чыгу өчен кирәкле 15 елның яртысын сатып алырга мөмкин. Пенсия яшенә җиткән кешенең иминият стажы яки пенсия баллары җитмәсә, картлык буенча иминият пенсиясенә чыгу биш елга кичектерелә.

Ут-су өчен түлисеме?

Минем студент оныкларым Чаллыда әбиләрендә пропискада тора. Тик алар анда бер көн дә яшәмәделәр. Балаларга 18 яшь тулгач, шул фатирга коммуналь түләү буенча бурыч җыелганын белдек. Эш шунда ки, идарәче оешма әҗәтне оныкларыма булган. Хәзер алар 200 мең сумнан артык акча түләргә тиеш. Берсе Казанда укый, икенчесе – Владивостокта. Студент бала ул акчаны ничек түләсен? Торакка приватизация ясалмаган. Фатирда пропискада торган өчен генә коммуналь түләү буенча җыелган бурычларны түләттерә алалармы?

Саимә МОРАТОВА. Чирмешән районы Кара Чишмә авылы

«Татарстанда ТКХ өлкәсендә иҗтимагый контроль төбәк үзәге» ассоциациясе:
– Фатирда пропискада булу бу торакта яшәү хокукы белән беррәттән, аның өчен түләү бурычын да йөкли. Өстәвенә бу очракта торак рәсмиләштерелмәгән, ул муниципаль милек булып санала һәм аннан файдаланган өчен түләү мәҗбүри. Оныкларга барыбер түләргә туры киләчәк.

Артистлар кайда?

Дәрвишләр бистәсендәге мәдәният йорты 2020 елда капиталь төзекләндерүдән соң бик матур булып ачылды. Ни кызганыч, анда барып кына булмый. Безгә артистлар килми. Концертларны телевизордан гына карарга туры килә. Клубка йөрүче дә күп югыйсә. Ремонт беткән елны Эльмира Сөләйманова концертына бер барган идек, шуның белән шул.

Фәһимә САБИРОВА

Рафис Фазылҗан, Дәрвишләр бистәсендәге Сәетгалиев исемендәге мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе:
– Безгә килергә теләгән артистларның берсен дә борып җибәрмибез. Һәркайсына ярдәм итәргә, концертларын тиешенчә оештырырга тырышабыз. Әмма соңгы елда килергә теләк белдерүче артистлар бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Бәлки, чыннан да, бүген кешедә концерт кайгысы түгелдер. Арада концерт вакытын гел күчереп, ахыр чиктә, гомумән юкка чыккан артистлар да булды. Ә халык мәдәният йортына йөри. Мәсәлән, бездә 50 төрле түгәрәк кенә эшли. Зурлар белән дә, балалар белән дә шөгыльләнәбез. Татар халык театры эшли, татар җыр һәм музыка ансамбле, рус театры, рус хоры, бию коллективлары бар. Шәһәр мәйданнарында да күп чыгыш ясыйбыз. Артистларга килгәндә, бу бездән тормый. 450дән күбрәк урынлы зур залыбыз, капиталь төзекләндерүдән соң ачылган 120 урынлы кинозалыбыз бар, рәхим итсеннәр!

Эльвира ВӘЛИЕВА әзерләде

Укучы сүзе

СТУДЕНТЛАР КӨНЕ УҢАЕННАН ГАЗЕТАДА УТКӘРЕЛГӘН СОРАШТЫРУГА КАЙТАВАЗ

Әйе, студент еллары, тулай торак безне тормышта кирәк булачак бөтен һөнәрләргә дә, мөстәкыйльлеккә дә өйрәтте. Ә менә балаларны җәлләмәскә кирәк, дип дөрес әйткән Илсөя Бәдретдинова. Ярату – бер, ә үзем дә күп авырлык күрдем әле, дип җәлләп үстерү – бөтенләй икенче нәрсә. Әни мәрхүмә әйтә торган иде: мал-туарны кызгансаң – йортыңны пыран-заран китерә, баланы җәлләсәң – башыңа менеп утыра, дип. Шул инде ул.

Гакилә НУРЕТДИНОВА

БАУЛЫ РАЙОНЫНДА УТКӘРЕЛГӘН «ГОРЕФ-ГАДӘТ – ИЗГЕ МИРАС» БӘЙГЕСЕ ТУРЫНДАГЫ ЯЗМАГА КАЙТАВАЗ

Мин хәзер дә оекбаш белән кызыл эчле галош кияр идем әле. Казанда болай йөреп булмый шул. Яшь чакта авылга кайткач, клубка рәхәтләнеп кызыл эчле галош киеп чыга идек. Хәзер исә ул чакларны искә алып сөйләргә генә калды.

Әдилә ХӘЛИУЛЛИНА

6 февраль | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АЛМАШ» 16+
10.00, 23.00 «КЛЮЧ К ЕГО СЕРДЦУ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ДИГӘН ЯЗМЫШ» 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 16+
19.00, 01.10 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
23.50 «Соотечественники» 16+
00.45 «Каравай». Уникальный промысел 6+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». Телевизион нәфис фильм 16+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Евгений Миронов, Александр Робак, Владимир Ильин. «ПРОБУЖДЕНИЕ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Максим Аверин, Мария Куликова, Елена Яковлева, Андрей Ильин, Мария Порошина, Нина Усатова, Дмитрий Ульянов, Игорь Бочкин, Анна Якунина, Эммануил Виторган, Ольга Павловец, Дмитрий Миллер, Константин Юшкевич, Владимир Жеребцов, Александр Сирин, Екатерина Травова. «СКЛИФОСОВСКИЙ. ЮБИЛЕЙНЫЙ СЕЗОН» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
00.10 Премьера. «Гиена Европы». Фильм Алексея Денисова 16+
00.55 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.30 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Дж. Бельтран – Ф. Тейт. Трансляция из США 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 15.25, 16.50, 19.50, 22.45 Новости
07.05, 19.00, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 04.30 Специальный репортаж 12+
10.25 Профессиональный бокс. Д. Лебедев – В. Рамирес. Трансляция из Москвы 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «География спорта. ОАЭ» 12+
13.50 «Что по спорту? Кемерово» 12+
14.25 Мировой футбол. Обзор 0+
15.30 «Громко». Прямой эфир
16.55 Футбол. «Winline Зимний кубок РПЛ». «Сочи» – «Ростов» (Ростов-на-Дону). Прямая трансляция из ОАЭ
19.55 Футбол. «Winline Зимний кубок РПЛ». «Краснодар» – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция из ОАЭ
22.50 Смешанные единоборства. UFC. Фрэнсис Нганну. Лучшее 16+
23.55 Конный спорт. «Dubai World Cup Carnival». Трансляция из ОАЭ 0+
00.50 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – «Зенит» (Санкт-Петербург) 0+
02.50 Новости 0+
02.55 «Легенды бокса с Владимиром Познером» 16+
04.50 «Громко» 12+

НТВ

04.50 Остросюжетный сериал «ДЕМОНЫ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ» (S) 16+
22.00, 00.00 Сергей Марин, Зоя Бербер, Сергей Чирков «ДУШЕГУБЫ» (S) 16+
00.25 Антон Васильев в детективе «НЕВСКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.20 «Давай разведёмся!» 16+
09.20 «Тест на отцовство» 16+
11.30 «Понять. Простить» 16+
12.35 «Порча». «Отведи глаза» 16+
13.05 «Знахарка» 16+
13.40 «Верну любимого» 16+
14.15 «Голоса ушедших душ» 16+
14.50 «И РАСЦВЁЛ ПОДСОЛНУХ...» 16+
19.00 «ПО ТОНКОМУ ЛЬДУ» 16+
23.00 «Голоса ушедших душ» 16+
23.35 «Порча» 16+
00.10 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «ПЯТЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
04.15 «БЕЗОТЦОВЩИНА» 16+
05.45 «6 кадров» 16+
05.55 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ЛЕГЕНДА ДЛЯ ОПЕРШИ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня. 16+
09.20, 01.10 «КАРЬЕРА ДИМЫ ГОРИНА» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
13.45, 15.05 «ПРАВО НА ПОМИЛОВАНИЕ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Мотоциклы особого назначения. История почетного эскорта». Документальный фильм. 1-я серия 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Украина-католическое наступление» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «АЛЛЕГРО С ОГНЕМ» 12+
02.50 «СКАЗКА СТРАНСТВИЙ» 12+
04.35 «Россия и Китай. «Путь через века». Документальный фильм 6+

7 февраль | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АЛМАШ» 16+
10.00, 23.00 «КЛЮЧ К ЕГО СЕРДЦУ» 16+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ДИГӘН ЯЗМЫШ» 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» – «Ак барс». Прямая трансляция 0+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 16+
00.15 «Соотечественники». Рафаэль Юнусов. Народный директор 16+
00.40 «Каравай». Мастер этнохудожественного кадра 6+
01.05 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». Телевизион нәфис фильм 16+
15.30 «Таяну ноктасы» 16+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Многосерийный фильм «ПРОБУЖДЕНИЕ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Максим Аверин, Мария Куликова, Елена Яковлева, Андрей Ильин, Мария Порошина, Нина Усатова, Дмитрий Ульянов, Игорь Бочкин, Анна Якунина, Эммануил Виторган, Ольга Павловец, Дмитрий Миллер, Константин Юшкевич, Владимир Жеребцов, Александр Сирин, Екатерина Травова. «СКЛИФОСОВСКИЙ. ЮБИЛЕЙНЫЙ СЕЗОН» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ» 12+
03.50 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20 Новости.
07.05, 14.25, 21.45, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Профессиональный бокс. Д. Кудряшов – О. Дуродола. Трансляция из Казани 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Здоровый образ. Регби» 12+
13.50 «Что по спорту? Новосибирск» 12+
16.25 «Ты в бане!» 12+
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Салават Юлаев» (Уфа) – ЦСКА. Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» (Нижнекамск) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
21.55 Футбол. Клубный чемпионат мира. 1/2 финала. Матч с участием «Фламенго» (Бразилия). Прямая трансляция из Марокко.
00.50 Баскетбол. Единая лига ВТБ. МБА (Москва) – УНИКС (Казань) 0+
02.50 Новости 0+
02.55 «Легенды бокса с В. Познером» 16+
04.30 «Человек из футбола» 12+
05.00 «Один за пятерых». Документальный фильм 6+

НТВ

04.55 Алексей Чадов, Юлия Снигирь, Сергей Пускепалис. «ОПЕРЕТТА КАПИТАНА КРУТОВА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ» (S) 16+
22.00, 00.00 Детективный сериал «ДУШЕГУБЫ» (S) 16+
00.25 Детектив «НЕВСКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.45 «Давай разведёмся!» 16+
08.45 «Тест на отцовство» 16+
10.55 «Понять. Простить» 16+
12.00 «Порча». «Андрюша» 16+
12.30 «Знахарка» 16+
13.05 «Верну любимого» 16+
13.40 «Голоса ушедших душ» 16+
14.15 Скажи, подруга 16+ Ток-шоу
14.30 «ВЫШЕЛ ЁЖИК ИЗ ТУМАНА...» 16+
19.00 «СЛУЧАЙНЫЙ БРАК» 16+
23.00 «Голоса ушедших душ» 16+
23.35 «Порча» 16+
00.10 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «МЕНЯ ЗОВУТ САША» 16+
04.20 «6 кадров» 16+
04.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «КЛАССНЫЕ ИГРЫ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.10 «ЕКАТЕРИНА ВОРОНИНА» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
13.45, 15.05 «НЕ ПОКИДАЙ МЕНЯ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Мотоциклы особого назначения. История почетного эскорта». Документальный фильм. 2-я серия 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «АТЫ-БАТЫ, ШЛИ СОЛДАТЫ...» 12+
02.45 «АЛЛЕГРО С ОГНЕМ» 12+
04.15 «Вымысел исключен. Век разведчика». Документальный фильм 12+

ЯЛЫМ ЖӘЛ ТҮГЕЛ СИҢА

Россиядә яшәүче ир-атларның өчтән бере хатыннарына йорт тирәсендәге эшләрне башкарырга ярдәм итә. SuperJob хезмәте уздырган сораштыру нәтиҗәләре шул хакта сөйли.

Сораштыруда барлыгы мең ир-ат һәм мең хатын-кыз катнашкан. Кияүдә булган ун хатын-кызның өчесе генә ирләренең үзләренә бар эштә дә ярдәм итүе турында әйткән. Шул ук вакытта ирләрен йорт эшләре белән кирәгеннән артык шөгыльләнә, диюче хатын-кызлар да бар. Алар – 36 процент. Шунысы кызык: мондый хатын-кызларның саны 2010 елдан бирле 9 процентка арткан. Ә ирләреннән ярдәм күрмәүче хатын-кызларның саны, киресенчә, 5 процентка кимегән.

Гомумән алганда, сораштыруда катнашучыларның күпчелеге өйдәге эшләрне ир-атныкына яисә хатын-кызныкына бүлеп карауның кирәген тапмый икән. Әйтик, сораштыруда катнашкан ир-атларның 63 проценты бернинди эштән дә (табак-савыт юу, ашарга пешерү, ремонт һ.б.) курыкмый. Хатын-кызлар исә башкачарак җавап биргән. Аларның бары тик 30 проценты гына ирләренең өйдәге бөтен эшне дә башкаруын әйткән.

Шунысы кызык: коронавирус пандемиясе чорында ир-атлар өй тирәсендәге эшләрдә күбрәк булышкан.

Сезнең фикерегезчә, ир-ат өй тирәсендә нинди эш башкарырга тиеш?

Җаваплар:	Ир-атлар	Хатын-кызлар
Бөтен төрле эшне дә	63%	48%
Ремонт, ир-ат эшен	19%	23%
Бернинди эшне дә	4%	4%
Өй җыештыру	5%	10%
Ашарга пешерү / аш бүлмәсендә ярдәм итү	3%	6%
Үзем ошый торган эш	4%	6%
Табак-савыт юу	1%	4%
Чүп түгү	2%	4%

vk.com

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры

САДЫЙКОВ
Марат Наил улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе коллективы, элеккеге хезмәттәшебез

ШӘМСЕТДИНОВА
Флёра
Нигъмәтулла кызы

вафат булу сәбәпле, гаиләсенең һәм туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

БЕР ЭЧКӘНЧЕ, ИКЕ УЙЛА

Арыганда көч өсти, күңелне күтәрә. Ул булганда, бернинди дару да кирәк түгел кебек. Шуңа күрә аның зыяны да юк сыман. Сүзебез – күпләрнең яраткан эчемлеге каһвә турында. Соңгы вакытта аппараттан каһвә сатып алып, аны аягүрә генә эчү бигрәк тә популяр. Болай эшләүдән организмыбызга файда бармы? Кайсы очракларда каһвәдән бөтенләй баш тарту хәерле?

Табиб-гастроэнтеролог Индира ГЫЙМАЛТДИНОВА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Каһвәнең нинди файдасы бар?

– Каһвәнең сәламәтлеккә әллә ни файдасы юк. Кан басымын, кәефне күтәрергә кирәк булганда ярап куя ул. Моның өчен каһвә составындагы кофеинга рәхмәт әйтергә кирәк. Соңгы тикшеренүләр каһвәнең бавырга файдалы булуын күрсәткән.

:: Атлаган саен каһвә эчү нәрсәсе белән куркыныч?

– Аны чамасыз кулланганда, иң беренче чиратта кешенең бит тиресе үзгәрә. Ул сорылана, төссезләнә. Каһвә кан тамырларын тарайта. Бу исә күз күрүен боза. Кеше начаррак, тоныграк күрә башлый. Бу сүзләрнең дөреслегенә инану өчен, махсус тикшерү дә уздырып карарга мөмкин. Өч атнага каһвәдән баш тартса, кешенең тән тиресе дә, күрүе дә яхшырачак. Бу эчемлекне үз итүчеләрнең игътибар иткәне бардыр: каһвә эчкәч, бераз күңел болгана, кикертә, эч күбә, авызда ачы тәм кала. Бу – үт куыгына зыян килгән дигән сүз.

:: Каһвә эчүнең көнлек нормасы бармы?

– Көненә фәлән кадәр генә эчәргә кирәк дигән чикләү юк. Шулай да аның күләме 200 миллилитрдан артмаса, яхшы. Аны сөт кушып сыегайтсаң, зыяны азрак булачак. Каһвәне көннең беренче яртысында – көндезге сәгать уникегә кадәр эчү хәерле. Каһвә организмнан суны чыгара. Шуңа күрә бер стакан каһвә эчкәннән соң, ике стакан чиста су эчеп куярга кирәк.

:: Аппараттан сатып алып, баскан килеш кенә эчелгән каһвәнең файдасы күбрәкме, зыяныммы?

– Андый каһвәнең файдасы юк диярлек. Үзең пешерә торган, бөртеклесенә өстенлек бирергә кирәк. Ул күпкә файдалырак.

КАЙСЫ ОЧРАКЛАРДА КАҺВӘ ЭЧҮ ТЫЕЛА?

➤Хәвефле чакта. Каһвәдә кофеин күп. Ул исә кешене уятып җибәрә, дәрт өсти. Шуңа күрә артык эмоциональ, хәвефле кешеләргә каһвә эчү киңәш ителми. Әлеге эчемлектән соң аларның хәле тагын да авыраячак.

➤Кан басымы югары булганда. Каһвә кан басымын күтәрә. Шуңа күрә кан басымы болай да югары булган кешеләргә аның ни дәрәҗәдә зыянлы икәнен күз алдына китерәсездер.

➤Ашказанында, уникеилле эчәктә җәрәхәт булганда. Каһвә ашказанының, эчәклекнең лайлалы тышчасын ярсыта. Әлеге эчемлек йогынтысында җәрәхәт тә начар төзәлә. Ул эчәклекләргә дә тискәре йогынты ясый. Бигрәк тә эч күбүдән интеккән кешеләргә сак булырга кирәк.

➤Сидек юлы авырулары вакытында. Каһвә составындагы кофеин бу очракта авыруны тагын да көчәйтәчәк. Ник дигәндә, ул сидек кудыру үзлегенә дә ия. Калкансыман биз авыруы, сөяк белән хилафлыклар булганда да каһвә эчүдән тыелып тору хәерле. Ник дигәндә, әлеге эчемлек сөякләрдәге кальцийны юып төшерә. Моннан тыш, ул калкансыман биз эшчәнлеген дә боза.

➤Анемия. Азканлылыктан интеккән кешеләргә дә каһвә белән дуслыкны өзәргә киңәш ителә. Кофеин тимернең организмда үзләштерелүенә комачаулый.

Сорау – җавап

ӘЗЕРЕ ФАЙДАЛЫМЫ?

?Соңгы арада күзем начар күрә башлады. Күзлек алмыйча булмый. Аның әзерен генә сатып алсаң, зыяны юкмы икән?

РЕЗЕДА К. Казан

Сорауга табиб-офтальмолог Суфия Җаббарова җавап бирде:

– Әзер күзлекнең бер уңай ягы бар. Әйтик, рецепт буенча ясалган күзлегегез ватылган, сынган, югалган очракта, әз яңасына заказ биргәч, озак көтәргә кирәк булган вакытта тиз арада ярдәмгә килә ул. Әмма мондый әзер күзлекне 2–3 сәгатьтән дә озаграк кияргә ярамый. Аларның стандарт күрсәткечләре бернигчек барлык кешеләргә дә туры килә алмый. Моннан тыш, әзер күзлекләргә, гадәттә, арзан, начар сыйфатлы линзалар куела.

Линзалары сыйфатсыз булган, диоптрияләр, күз каралары арасы дөрес булмаган әзер күзлекләр сурәтнең бозылуына һәм томанлы булып күренүенә генә түгел, ә җитдирәк нәтиҗәләргә китерә ала. Аерым алганда, кешенең күзләре кызара, яшь ага. Күз авырулары пәйда булырга, баш авырту, мигрень, баш әйләнү кебек билгеләр күзәтелергә, кан басымы күтәрелергә мөмкин. Шуңа күрә күз табибына мөрәҗәгать итеп, нәкъ менә сезгә туры килгән, сыйфатлы күзлеккә заказ бирергә кирәк.

Буыннар сызлаганда нәрсә ашарга?

Ярый	Ярамый
Буыннары авыртканнарга диңгез кәбестәсе, креветка, койка (холодец), алма (кабыгы белән) ашарга киңәш ителә.	Итнең майлы сортларын, кыздырылган ризыкларны, төче газлы суларны, туңдырманы рационнан алыгыз.
В витамины терәк-хәрәкәт системасын ныгыта, әлеге витамин сөт продуктларында, йомырка, балык, бавыр, яшелчәләрдә бар.	Составында фосфат булган ризыкларны ашамагыз, фосфат организмда җыелып бара һәм остеопороз китереп чыгара. Мондый продуктларга куертылган сөт (сгущенка), спиртлы эчемлекләр, йомшак сыр (плавленый), краб таякчыклары, чүпрәле ак күмәч, казылык керә.
А витамины фосфор белән кальцийны үзләштерергә булыша. Ул кызыл төстәге продуктларда күп: болгар борычы, помидор, абрикос, кызыл ит, брокколи, сыр, балык, кишердә.	Кузгалак, шпинат, редистан да баш тартыгыз, чөнки аларда буыннар өчен зарарлы булган кузгалак кислотасы бар.
С һәм Е витаминнары организмдагы тернәкләнү процессларын тизләтә, ялкынсынуны бетерә. Организмыгызны әлеге витаминга баету өчен, рационыгызга алма, гөлҗимеш, цитруслар, чөгендер, брокколи, манго һәм үсемлек мае кертегез.	Составында пурин булган продуктларны да сак кулланыгыз: каһвә, кара һәм яшел чәй, шоколад, бавыр.
Кальцийны үзләштерү өчен, D витамины кирәк. Аны йомырка сарысыннан, сыер маеннан һәм эремчектән эзләгез.	Кыздырылган әйбер урынына парда пешкәнен ашагыз, газлы суны сок яки компотка алыштырыгыз, татлы ризыклардан күрәгә, кара җимешкә күчегез.
Магний нерв системасы өчен җавап бирә, терәк-хәрәкәт аппараты эшчәнлеге аңа турыдан-туры бәйле. Әлеге микроэлемент карабодайда, ногыт борчагы, чикләвек, ачы шоколадта бар.	Тозны да чамалап кына ашарга кирәк, чөнки ул организмда сыеклыкны тоткарлый.
Буыннар сәламәтлеге өчен омега-3 тә кирәк. Аның өчен әстерхан чикләвеге, арахис, майлы балык, үсемлек маен кулланыгыз.	

Чәчне тәрбиялибез

Чәч ялтырап торсын өчен: бер чынаяк кефирны кайнар сулы тәлинкәдә тотып җылытыгыз да аңа биш тамчы кастор мае тамызыгыз. Катнашманы чәчегезгә сылагыз да полиэтилен башлык киеп, өстеннән сөлге урагыз. Ярты сәгатьтән соң чәчегезне юыгыз.

Чәч коелганнан: бер өлеш үсемлек маена ике өлеш аракы кушып, шуны чәч төбенә сылагыз.

Кавыктан котылу өчен: бер стакан кайнар кара чәйгә бер чәй кашыгы кастор мае һәм 20 грамм аракы салып болгатыгыз да аннары чәчегезгә сылагыз. Бер сәгатьтән соң юыгыз.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ПОМИДОР ИРКӘЛӘҮНЕ ЯРАТМЫЙ

Бакчачылар әкренләп эшкә тотына. Петуния ише вак орлыклы чәчәкләр, борыч чәчү мәшәкате белән йөри алар хәзер. Хәер, помидорны да мартта түгел, ә февральдә үк чәчеп куючылар күбәйде. Тизрәк чәчсәң, уңышын да иртәрәк җыеп алуга өметләнеп була. Ә өметләр аклансын өчен, томатны алданрак кына түгел, ә бөтен хасиятен китереп чәчәргә һәм үстерергә кирәк. Һәвәскәр бакчачы Гөлфия НУРИӘХМӘТОВАдан шул хакта белештек.

Гөлфия ханым әйтүенчә, мул уңыш сере иң элек орлыкны ни дәрәҗәдә сыйфатлы итеп чәчүгә әзерләүдән тора. Ничек итеп, дисезме?

Беренчедән, орлыкларны кар суын җылытып, шунда җебетергә кирәк. Юкса помидор орлыгы авыр тишелә.

Икенчедән, суыкта һәм җылы суда чиратлаштырып тотып, чыныктырырга. Орлыкларны җылы кар суында бүлмә температурасында бер көн (12–18 сәгатьтән арттырырга ярамый, юкса зыян киләчәк) тоталар, аннан соң, кечкенә генә тукыма капчыкка салып, төнгә суыткычка (+3 градуска) куеп калдыралар. 5–7 көн дәвамында шулай кабатлап торалар. Шушы вакыт эчендә орлыкларның юеш булып калуы шарт, ди бакчачы.

Шул рәвешле чыныктырганнан соң, орлыкларны дымлы җиңел туфраклы савытка 1–1,5 см тирәнлеккә чәчәргә мөмкин. Сай чәчкәндә, орлык тышчасы туфрак өстенә чыгып, үсентенең үсүен тоткарлый. Аннан соң, парник эффекты булдыру өчен, савытның өстен пленка белән каплыйлар һәм җылы урынга куялар. Чәчү өчен утә күренмәле пластик савытлар бик уңайлы. Савытларның өстен көн саен ачып җилләтәләр. Орлыкларның тишелүе өчен иң әйбәт температура – 24–25 градус.

Гөлфия Нуриәхмәтова әйтүенчә, безнең якларда түбәндәге сортлар әйбәт үсә һәм мул уңыш бирә.

Иртә өлгерешле сортлар: Снегирь, Афродита F1, Дон Жуан, Лабрадор, Золотой поток (сары).
Теплица өчен: Диджей F1, Минусинский крупный, Толстой F1, Загадка, Розовый мед.
Ачык грунт өчен: Монгольский карлик, Казанова, Перцевидный крепыш, Демидов, Каменный цветок F1, Беталюкс.

Тәүге шытымнар күренүгә, пленкасын алып, савытны яктырак урынга куялар. Шуннан соң инде, Гөлфия Нуриәхмәтова кистереп әйткәнчә, үсентеләрне иркәләүдән файда юк! Һава температурасының +19...+20 градус, төнлә исә 1–2 градуска түбәнрәк булуы әйбәт. 3–4 тәүлектән соң, шытымнар бераз ныгыгач, көндезге температураның +18...+19, төнлә +17...+18гә калуы яхшы. Берочтан бакчачы өйдә мондый шартларны тудыру серләрен дә аңлатты. Моның өчен көндез үсентеләрне көяшлы тәрәзә төбендә тотарга, ә төнгә, кухня идәненә куеп, форточканы ачып калдырырга мөмкин.

vk.com

Бакчачы Нурия МИСАЛИМОВА:



– Яңа ел бәйрәмнәрендә дә, аңа кадәр һәм шуннан соң да фатирыбыз «бакча»сында үсеп утыручы Черри помидорыннан өзелгәнебез юк. Помидор үсентесен елына ике тапкыр: башта бакча помидорлары беткәнче – сентябрь айларында, аннан февраль башларында утыртам. Тиз өлгерешле, тәбәнәк сортларын сайлап алам. Пластик савытка туфрак тутырып, орлыклар төртәм дә, су сибеп, капкач яки пленка белән каплап куям. Ике зур яфрагы күренгәч, үсентеләрне күчереп утыртам. Бераз үскәч, үсентенең очын чеметеп кенә өзеп алам. Аена бер тапкыр комплексль ашлама кертәм. Көньяк яки көнбатышка карап торган тәрәзә төпләрендә үстерәм. Өй шартларында помидор үстерүнең моннан да уңайлы ысулы юктыр, дип уйлыйм.

Ә инде чын ике яфрагы күренүгә, үсентеләрне күчереп утыртырга вакыт җиткәнен барыбыз да беләдер. Соңрак та мөмкин, ләкин үсентеләр кояш яктысы өчен ярыша-ярыша үсә башлаганчы кирәк. Савытка туфракны яртылаш кына тутырып (өстәп торырга кирәк булачак), үсентене тирәнгәрәк утырту хәерлерәк.

Белеп тор!

Саф һава сере

Өебезнең һәр бүлмәсендә диярлек телевизор яки компьютер, төрле көнкүреш техникасы бар хәзер. Даими чистартып-җыештырып тору да өй һавасында чистарткыч сыекчалардан бүленеп чыккан матдәләр туплануга китерә. Шулай ук мебель, келәм, пластик тәрәзәләр зарарлы матдәләр бүлеп чыгара. Зыянлы нурланыштан котылырга, бүлмәдәге һаваны чистартырга гөлләр бик нык ярдәм итә.

Нинди гөлләр, дисезме? Барыбызга да таныш яран, йөзьяшәр (алоэ), мирт, драцена, антуриум һаваны формальдегид, аммиак, бензол кебек «химия»дән чистарту үзенчәлегенә ия.

Аш-су бүлмәсе һавасын төтен, яну продуктлары һаман саен пычратып тора. Мондый зарарлы матдәләрдән хлорофитум, аглаонема, азалия гөлләре коткара. Үзенә бер өй экологлары кебек: бик күп углекислый газны, пластик тәрәзәләрдән, линолеумнан чыккан «химия»не йота, хәтта

зарарлы микроорганизмнарны юкка чыгара алар. Йокы бүлмәсе һавасын чистартуга традесканция, йөзьяшәр, ала миләүшә (фиалка), акча гөле, каланхоэ гөлләре бик нык ярдәм итә.

Ә менә дымлырак бүлмәдә хәтфә гөл (плющ) үстерүдән дә яхшысы юк. Ул күгәрек гөмбәчеген дә булдырмый.

Белгечләр әйтүенчә, бер бүлмәдә кимендә өч үсемлек булырга тиеш. Шул чагында өй һавасындагы зарарлы матдәләр бермә-бер кимеячәк.

Файдалы

ДАРЧИН ХИКМӘТЕ

Дарчин (корица) исен яратасызмы? Шулай икән, аны аш-суга гына түгел, башка максатта да куллана аласыз.

Порошок хәленә китерелгән тәмләткечне кечкенә генә банкага тутырып, капкач белән әйбәтләп каплагыз. Күңелегезне тынгысызлык биләп алган чакларда, ачып иснәгез. Дарчинлы тагын бер банканы һава сафландыргыч урынына тотарга мөмкин. Банка капкачын вакыт-вакыт ачып торсагыз, бүлмәгә хуш ис таралачак. Мондый «освежитель» кибетнекенә караганда күпкә файдалырак!

ЙОД КОТКАРА

Икмәк күгәрмәсен өчен нишләргә? Бер сере бар. Мамык кисәгенә 2-3 тамчы йод тамызып, киндер-сюрприз савытына салабыз. Без белән берничә урында тишек ясыйбыз да савытны полиэтилен капчыкка икмәк янына салабыз. Болай эшләгәндә, ипи атналар буе искермичә саклана.

Тәмле булсын!

«Бик тәмле» запеканкасы

Надежда СТЕПАНОВА рецепты

Кирәк: *300 г тавык яки күркә ите, эрерәк 2–3 бәрәңге, 2 баш суган, 1 йомырка, үсемлек мае, 100 г майонез, тәменчә тоз.*

Бәрәңгене, кабыгын әрчеп, озынча итеп турыйбыз да төбе үсемлек мае белән майланган тирән эчле табага салабыз. Тавык итен шакмаклап турыйбыз һәм бәрәңге өстенә тезәбез. Суганны, чистартып, ваклап турыйбыз һәм ит өстенә сибәбез.

Йомырканы сытып, майонезга кушабыз. Болгатабыз. Катнашманы табадагы ризыклар өстенә агызабыз. 180 градуска җылытылган газ мичендә 30–40 минут пешерәбез.

Исеңдә тот!

ЯШЕЛЧӘ ПЕШЕРӘ БЕЛӘСЕҢМЕ?

Винегрет һәм салат өчен яшелчәне, суы кайнап чыккач, салмак кына утта пешерергә кирәк. Көчле утта, тышы изелеп, уртасы чи кала. Суына берәр чеметем шикәр комы өстәп җибәрсәң, кишер-чөгендерләр бигрәк тә тәмле булып пешәчәк.

КӨНЛӘШҮ ӨЗМӘСЕН БӘГЫРЬНЕ

Адәм баласы барына канәгать булып кына яши алмый. Тормыш булгач, күз күргәч, фәләннең машинасына да, төгәннең малына да, хатынына да кызыгасың. Шуннан көнчелек хисе дә уяна. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәтта: «Ут утынны яндырган кебек, көнчелек изге гамәлләрне юкка чыгара», – дип тә кисәткән. Ни өчен безне көнчелек хисе биләп ала? Аннан котылып буламы?

Әлеге сорауларга «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН белән җавап эзләдек.

:: Динебездә көнчелек, көнләшү турында ни диелә?

– Көнләшү – тыелган гамәл, ул Аллаһы Тәгалә каршындагы зур гөнаһлардан санала. Бу – Аллаһтан ерагайган, имансыз, икейөзле мөселманнарга хас сыйфат. Моны Коръән аятьләре һәм пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләре дә раслый. Аллаһы Тәгалә: «Әллә алар Аллаһның Үз юмартлыгыннан биргән бүләге өчен кешеләрдән көнләшәләрме? Без бит инде Ибраһимга китап һәм хикмәт бирдек. Шулай ук Без аңа олуг патшалык та бирдек», – дигән. Асылда, көнчелек ул – Аллаһка карата дошманлык хисе саклау, чөнки көнче кеше Аллаһның колына нигъмәт бирүен яратмый. Аллаһ бит ул нигъмәтне үзе бирә, ә көнче кеше аның юкка чыгуын тели. Шул сәбәпле ул Аллаһның тәкъдиренә каршы чыга. Менә шуңа күрә Иблис тә Аллаһның дошманына әверелгән, чөнки аның Аллаһка буйсынмавына бары тик тәкәбберлек һәм көнчелек сәбәпче булган. Җирдә кылынган иң тәүге гөнаһның да төп сәбәбе – көнчелек хисе бит. Кабил белән Һабил кыйссасы шуның турында сөйли. Шулай ук Йосыф пәйгамбәрне дә абыйлары көнләшү аркасында үтерергә теләгән һәм коега салган.

Көннәрдән бер көнне пәйгамбәребездән (с.г.в.): «Нинди кеше иң хәерле?» – дип сораганнар. «Иң хәерле кешеләр шулардыр, кемнең калебе мәхмүм һәм теле төзек», – дигән. «Әй, Рәсүлуллаһ, теле төзек дигәнне аңлыйбыз. Калебе мәхмүм дигән сүз нәрсә ул?» – дип сорау биргәннәр кабат. Пәйгамбәребез (с.г.в.) исә: «Бу кешенең калебе чиста. Анда гөнаһ, азгынлык, зарар һәм көнчелек юк», – дигән.

Тагын бер хәдистә: «Өч нәрсәдән бер кеше дә котылмаячак: көнчелек, кеше турында начар уйлау һәм кошларга карап юрау. Мин сезгә аннан чыгу юлын аңлатачакмын. Әгәр дә көнләшсәң, куралмау хисе саклама, әгәр дә кеше турында начар уйласаң, аның нигезендә бернәрсә дә эшләмә, әгәр дә кошларның очканын күрсәң, юлыңны дәвам ит», – диелә.

:: Көнләшү хисен бөтенләй бетереп буламы?

– Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Үзеңнән өстәгеләргә карап, аларның малына кызыкма, иң ярлы кеше булырсың. Аска карап, гыйбрәт ал, иң бай кеше булырсың, чөнки өстәгеләрне беркайчан да куып җитә алмыйсың», – дигән. Тормышыбыздан риза булырга өйрәнергә кирәк. Бу җиңел түгел. Бай кешенең дә байлыгы аның өчен зур сынау, фәкыйрь кешенең дә ярлылыгы – сынаудыр.

Аллаһы Тәгалә: «Үлгәннән соң мәхшәр мәйданына чыккач белерсез: кайсы хәерлерәк», – дигән. Ярлы кеше: «Я Раббым, миңа аз мал бирдең. Әгәр күп мал бирсәң, җәннәтеңә кермәс идем», – дияр. Бай кешенең байлыгы күп булгач, гөнаһы да күп була. Без Аллаһның хикмәтен аңламыйбыз. Кешеләрнең байлыгына игътибар итмичә, йөрәкне Аллаһы Тәгалә белән бәйләп, Аннан ризык, бәрәкәт бирүне сорарга кирәк.

islam.ru

:: Кешеләр арасындагы көнләшү – бер хәл, туган-тумачалар арасында да була торган күренеш бит бу хәзер.

– Аллаһы Тәгалә байлык, малны бар кешегә дә тигез итеп бүлеп бирмәгән. Моның үз хикмәте бар. Күпләр: «Ни өчен Аллаһы Тәгалә миңа аз биргән, туганыма күп биргән?» – диләр. Аллаһы Тәгалә һәрберебезнең дә эчке халәтебезне, уй-фикерләребезне белә һәм шуларга карап бирә дә. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кайбер адәм балаларына байлык хастыр. Әгәр малларын киметсәм, иманнарына зәгыйфьлек килер. Кайберләргә ярлылык хас. Әгәр байлык бирсәм, иманнарына зәгыйфьлек килер», – дигән. Ул кешесенә карата үлчәп биргән.

Без туганнарыбыз белән бик сирәк аралашабыз бит. Шуңа күрә дә аларның һәр малына сөенмибез, көнләшәбез. Бер-беребезгә карата нәфрәт хисе сакламыйк, бер-беребездән көнләшмик, дошманлашып, араларны бозмыйк.

Көнләшү артып китсә, шушы доганы укып, Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорыйлар:

«Әгузү бикәлимә́тил-лә́һит-тә́ммә́ти әллә́тй лә́ йүдҗә́үизүһүннә бәррун үә лә́ фә́җирун мин шәрри мә́ халәка үә бараъә үә зәраъә, үә мин шәрри мә́ йәнзилү минәс-сәмә́ьи үә мин шәрри мә́ йәгъруджү фй́һә́, үә мин шәрри мә́ зәраъа филь-ардыи үә мин шәрри мә́ йәхруджү минһә, үә мин шәрри фитәнил-ләйли үән-нәһа́ри, үә мин шәрри күлли та́рикин иллә́ та́рикан ятрукъу бихайрин, йә́ Рахмә́н!»

Мәгънәсе: «Ул бар кылган, булдырган һәм юктан бар иткән нәрсәләрнең явызлыгыннан, күктән төшкән һәм аңа күтәрелгән нәрсәләрнең явызлыгыннан, Ул җирдә бар кылган һәм аның эченнән чыга торган нәрсәләрнең явызлыгыннан, төн һәм көн фетнәләренең явызлыгыннан, төнлә килгән, үзе белән, и Мәрхәмәтле, яхшылык алып килгәненнән тыш, һәрнәрсәнең явызлыгыннан Аллаһның салих та, бозык кеше дә каршы тора алмаган камил сүзләренә сыенам.

Өч хәдис



«Аллаһы Тәгалә белемне яшь чакта бирә. Һәр яхшы әйбер яшь чакта бирелә».

«Әй адәм балалары! Әй минем өммәтем! Аллаһның ачуыннан куркыгыз һәм кыямәт көнендә гадел хөкем булачагына иман китерегез. Бер мөэмин икенче бер мөэмингә золым кылмасын. Әгәр дә якыннарыгызның берсенә карата золым кылган булсагыз, Аллаһ Сөбхәнә вә Тәгалә кыямәт көнендә, һичшиксез, моның җәзасын бирер!»

«Иманлы бәндәләр өчен кыш яз кебектер. Аның төннәре озын, бу аларны гыйбадәттә үткәрергә мөмкинлек бирә; көннәре кыска, бу аларны ураза тотып үткәрергә мөмкинлек бирә».

Соңгы теләк хикмәте

Хастаханә палатасында ике өлкән яшьтәге ир-ат инде берничә көн авыр хәлдә ята икән. Үзләре аңында, әмма шактый зәгыйфь кыяфәтләреннән үлем түшәгендә ятканнарын чамалап була. Яннарында – кайгыртучан хатыннары. Рәхмәт яугыры, икесе дә бик тырыш, мәрхәмәтле затлар. Шулай да, берсенә шактый читен, чөнки карты бик көйсез һәм сабырсыз булып, төрле начар сүзләр кычкырып, аның күңелен гел тырнап тора. Ә икенче бабай, хәле кыен булуга карамастан, тузем һәм тыныч, карчыгына күз тутырып, хәтта елмаерга тырышып карый.

Бер вакыт иртән ике авыру кеше хатыннарына үтенечләрен белдерде. Көйсез, әшәке сүзләр кычкырып ятучы кеше: «Кыздырылган балык ашыйсым килә, бүген үк алып кил!» – дип фәрман бирсә, тыныч, ипле бабай: «Мөмкин булса, сөт эчәр идем, җанашым...» – дигән үтенеч белдерә.

Карусыз хатыннар тормыш иптәшләренең шушы теләкләрен үтәп, алар сораган ризыкны алып киләләр. Беренчесе рәхмәтен дә әйтмичә: «Озак йөрдең, фәләнфәсмәтән!» – дип сүгенеп алып, хатыны алып килгән балыкны бик тәмләп ашый да... җан бирә. Икенчесе исә карчыгын: «И-и, ярый әле син бар дөньяда, җанашым, синнән башка нишләр идем икән...» – дип каршы алып, рәхмәтләрен укый-укый сөтне эчәм дип кулын сузуы була, ләкин... алам дигәндә генә чынаягы кинәт кулыннан ычкынып, сөте түгелеп китә.

Әби нәрсә булды икән дип караса – бабай җан тәслим кылган...

Шушы хәлгә шаһит булган фәрештәләр, соңыннан Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп, сорау бирә:

– Йә бөек Раббыбыз! Аңлатсаң иде безгә олуг хикмәтеңнең яшерен мәгънәсен: ни өчен гомерен кәферлектә үткәргән, башкаларга золым кылган шушы начар телле кешенең соңгы теләген үтәп, аңа балык ашаттың, ә Синә озак еллар дәвамында гыйбадәт кылып, кушканнарыңны үтәп, тыелганнарыңнан тыелып яшәгән шушы нурлы күңелле иманлы бәндәңнең соңгы теләген үтәмичә, аңа сөт эчәргә мөмкинлек бирмәдең?

Бу сорауга Аллаһы Тәгалә болай җавап биргән:

– Шушы кәфер заманында бер яхшы гамәл кылган иде. Шул бер изгелеге буш калмасын дип үтәдем дә инде Мин аның соңгы теләген. Әмма бакыйлыкта бу кешенең урыны – җәһәннәмдер. Миңа гыйбадәт кылып яшәгән кешенең исә җәзасын алмаган бер гөнаһы булды. Аның бу дөньядагы соңгы теләге үтәлмәве шул хатасына кәффарәт булып, әлеге гөнаһы гафу ителде. Бакыйлыкта исә бу итагатьле мөэминнең урыны – җәннәттер!

Дөрестән дә, әлеге кыйсса тирән мәгънәгә иядер. Кайвакытта: «Ни өчен дин тотмаучылар, агъни намаз укымыйча, ураза тотмыйча, гомумән, гыйбадәт кылмыйча гомер итүчеләр мул, бай тормышта яши, ә менә гыйбадәт әһеле булган мөселманнарның яшәү дәрәҗәсе әллә ни югары түгел?» – дип сорыйлар. Әлбәттә, ул гел алай түгел, шулай да мондый сорау бирүчеләргә болай җавап биреп булыр иде...

– Без сабыйларны 2 яшьтән кабул итә башлыйбыз. Бер генә төркем. Алар кашык тота белсә дә, подгузник кияләр. Тәрбиячеләр чүлмәккә утыртырга өйрәтә. Әти-әниләр балаларын бакчага бирергә бик ашыга, дияр идем. Үзләре дә әзер түгел, балалар да авырый. Кайбер сабыйлар ярты елда гына ияләшә. Әти-әниләргә больничныйда еш утырырга туры килә. Соңыннан, акча кирәк дип, тормыш кууларын үзләре дә аңлыйлар. Балаларга әни назы җитеп бетми. Кайберләре көн буена калдыра. Минемчә, иң әйбәте – сабыйны бакчага 4 яшьтән бирү. Бу вакытта бала сөйләшә дә, кешене дә аера белә. Тәрбиячеләр исә төрле яшьтәге балалар белән эшли ала.

МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ *(процентларда)*

	2 айдан 8 яшькә кадәр	2 айдан 3 яшькә кадәр	3 яшьтән өлкәнрәк
2019 ел (1 гыйнварга)	93,9	59,3	99,5
2020	91,8	60,7	97,4
2021	94,4	72,3	98,1
2022	97,3	81,6	100

КУЫП ҖИТӘРГӘ ҺӘМ УЗЫП КИТӘРГӘ!

Гыйнварда күренекле совет галиме, атом бомбасының «әти»се Игорь Курчатовның тууына 120 ел тулды. Бөек Ватан сугышы елларында ул Казанга эвакуацияләнә һәм аның мәңгелек эшләре башкалабызда эшләнә. Галимнең эшчәнлеге атом бомбасы ясау белән генә чикләнми, ул илебездә атомтөш фәненә нигез салучы буларак тарихка кереп кала.

Курчатов Казанда булганда атом бомбасы ясау буенча эшләренең күп өлеше Бишбалтадагы «Урак һәм Чүкеч» заводында башкарыла. Бу заводка очраклы гына килеп эләккән Кукмара егете Гарәфетдин Хисаметдинов нәкъ шул цехта башта слесарь, аннан, Казан авиация институтын тәмамлаганнан соң, җитәкче булып эшли. Соңрак партия оешмасын җитәкли. Завод турындагы мәгълүматларны берәмтекләп җыеп, музей төзи. Шул чакта әле «яшерен» грифы белән сакланса да, атом бомбасының заводка нindидер катнашы булганын чамалый. Без Гарәфетдин абый белән шул хакта сөйләшәбез.

«Урак һәм Чүкеч»

– Минем бу заводка килеп керүем, чыннан да, бик очраклы булды. Кукмарада татар мәктәбен бетергәч, Ижауга һөнәри училищега киттем. «5»кә генә укып бетердем. Җибәрәселәре килми генә бит. Мондый белгечләр үзебезгә дә кирәк, диләр. Ә минем Казанга кайтасым, укуымны да дәвам иттерәсем килә. Ул вакытта Казанда туганнан туган апам яши иде. Килеп кергәч, болай диде: «Әнә чык та 1 нче трамвайга утыр. Күперне чыккач, төшәрсең. Анда заводлар күп. Берсенә булмаса, икенчесенә алырлар». Ул әйткәнчә эшләдем. Беренче булып «Урак һәм Чүкеч»кә барып кердем. Һәм бөтен гомеремне диярлек шунда үткәрдем. Яшьрәк чакта атом бомбасы турында да, Курчатов турында да сөйләгәннәрен ишетмәдем әле. Гади эшчеләр бу хакта белмиләр иде булса кирәк. Музейга экспонатлар җыеп йөргәндә, бер олы яшьтәге җитәкче миңа: «Безнең заводта бик зур кешеләр булган, зур эшләр эшләнгән. Бу хакта әлегә белми торуың хәерлерәк булыр. Мин сиңа сөйли алмыйм», – дип, серле генә әйтеп куйды. Образлы әйткәндә, туфракка орлык салып куйган кебек булды инде бу. Шытып чыксын өчен, тагын да эзлеклерәк, игътибарлырак булып киттем. Кызыксына торгач, Курчатов турында да ишеткәләдем. Тик бу хакта кычкырып сөйләшергә ярамый иде әле. Игорь Васильевичның Казанда эшләве турында рәсми төстә беренче тапкыр тарихчы галим Булат Солтанбәков язмасыннан укып белдем. Ул КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Усманов белән Мәскәүгә бара һәм аңа репрессиягә кагылышлы, моңа кадәр яшерен дип саналган документлар белән танышырга мөмкинлек бирәләр. Шунда ул «Урак һәм Чүкеч» заводы турындагы белешмәләргә юлыга. Соңрак тарихчының балалары белән аралашырга да җай чыкты. Бишбалта тарихын өйрәнеп, китап чыгарырга җыену сәбәпле, Игорь Курчатовның Казандагы язмышын ныклап өйрәндем.

1941 елның июль башында илебез хөкүмәте СССР Фәннәр академиясе президиумын, Мәскәү һәм Ленинградтан 17 фәнни-тикшеренү институтын, шулай ук Белоруссия Фәннәр академиясен Казанга эвакуацияләү турында карар кабул итә. Бу эшне башкарып чыгуны академик Отто Шмидтка тапшыралар. Ул, 1941 елның 19 июлендә эвакуацияләнгән беренче төркемне кабул итү өчен, Казанга килә. Университет аудиторияләрендә матраслар җәелгән 1500 караватт урнаштыралар. 28 июль көнне кешеләр төялгән беренче эшелонны кабул итә. Шәһәргә барлыгы 33 фәнни учреждение күчерелә. Казанда халык саны 401 меңнән 515 меңгә җитә. СССР Фәннәр академиясеннән гаиләләре белән 5 мең хезмәткәр килә. Алар арасында 39 академик һәм 44 әгъза-мөхбир була. Шулай итеп, хәрби тематика һәм фәнни тикшеренүләр буенча актив эшләр башлана.

Курчатов

Игорь Курчатов Казанга 1942 елның 9 гыйнварында тәнлә белән килә. Урамда бик салкын, транспорт йөрми, аң тимер юл вокзалыннан шәһәр үзәгендәге Школьный (бүгенге Катановский) тыкрыгына җәяү барырга туры



килә. Андагы 2 нче йорттан галимгә ике бәләкәй генә бүлмәсе булган коммуналь фатир бирәләр. Хатыны Марина Дмитриевна белән энесе Борис алданрак килгән булалар.

Гыйнвар салкынындагы бу «сәяхәт» эзсез югалмый. Икенче көнне Курчатов, температурасы күтәрелеп, урынга егыла. Өйдәгеләр башта салкын тигән дип уйлыйлар, тик хәлләр җитдирәк була: галим тиф белән авырып китә. Азрак хәле җиңеләйгәч, учетка басарга дип, хәрби комиссариатка юл тота. Ә ярты сәгатьтән күршеләре аны чанага салып алып кайталар – үпкәләре ялкынсынган… Казан табиблары тырышлыгы белән ул аякка баса.

Эшләргә рөхсәт алу белән, Игорь Васильевич самолетларны, танкларны, корабльләрне саклау буенча Севастопольдә башлаган эшен дәвам иттерә. Аның бигрәк тә конструктив танк бронясы ясау буенча тикшеренүләре әһәмияткә ия. Моның өчен Курчатов физика-техника институтының броня лабораториясен җитәкли. Аңа Карл Маркс урамында урнашкан КАИ бинасының подвалында 500 кв. м зурлыгындагы мәйданны бүлеп бирәләр. Сынауларны Киевтан эвакуацияләнгән Танк ремонтлау заводы полигонында үткәрәләр. Аның корпуслары хәзер Казан авыл хуҗалыгы институтының Ферма-2 дип аталган участогына урнаштырыла. Моннан тыш Курчатов җитәкчелегендә Казанда җитештерелгән Пе-2, Пе-8, У-2 самолетларына ягулык бакларын урнаштыру тәртибе үзгәртелә. Яшел Үзәндә җитештерелүче торпедо һәм катерларны саклауны көчәйтү буенча техник таләпләр кертелә. Һәм боларның барысы да бер ел эчендә башкарыла. Чөнки Курчатов әйдәп баручы галим генә түгел, бик оста оештыручы да, җитәкче дә була. Бу мәсьәләләрне хәл итү өчен, ул илдәге институтларны, заводларны, җитәкчеләрне җәлеп итә.

Галим СССРда беренчеләрдән булып атом-төш физикасын өйрәнә башлый. Аның җитәкчелегендә 1939 елда илдә беренче циклотрон төзелә, ә 1940 елда корабльләрне минадан саклау эшләнмәләре җитештерелә. Сугыштан соң исә Европада беренче атом реакторы (1946 елда), СССРда беренче атом бомбасы (1949), дөньяда беренче термик төш бомбасы (1953) һәм атом электростанциясе (1954) төзелә. Ул Атом энергиясе институтына нигез сала һәм аның беренче директоры була. Советлар Союзының көчле атом державасына әверелүе нәкъ менә Курчатов исеменә бәйле.

Яшерен лаборатория

1942 елның октябрендә хөкүмәт боерыгы нигезендә Курчатовны тиз арада Мәскәүгә чакырып алалар, чөнки хәрби разведчиклар һәм дипломатлар атом проблемалары буенча яшерен документларга юлыгалар. Ул вакытта моңа кагылышлы эш берничә илдә алып барыла. Документлардагы формулаларның һәм исәп-хисапның очына чыгар өчен белгечләр кирәк һәм андыйларның берсе Курчатов була. Бу кыйммәтле документларны өйрәнгәннән соң, галим Америка һәм Германия белгечләренең атом бомбасын җитештерү мәсьәләсен менә-менә хәл итәчәкләрен, ә Советлар Союзының алардан 2–3 елга артта калганын әйтә. Курчатов отчетын укыганнан соң, Сталин белән Берия аңа, Американы куып җитәргә һәм узып китәргә, дигән бурыч куя.

Шушы максаттан Курчатов Казанда, КАИ подвалында урнашкан 2 нче лабораторияне җитәкли. Берия аңа бу лабораториянең ни өчен 2 нче номерлы икәнен дә аңлата. «Беренчесе – без. Мәскәү Кремлендә!» – ди ул. Аннан соң 3 нчесе дә, 4 нчесе дә була… Алар барысы да атом коралы ясау белән шөгыльләнә. Әйтергә кирәк, бу лаборатория инде 1942 елның 12 апрелендә үк оештырылган була. Дәүләт оборона комитеты карары белән аңа 2 нче номер гына бирелә. Ә Ленинград физика-техника институты директоры Абрам Иоффе институтның яшерен режимда эшләүче Казан төркеме буенча боерык чыгара. Ленинградтан 20 кг уран, җиһазлар кайтарыла һәм ул заводтан ерак түгел ике катлы бинага урнаштырыла. Курчатовка атом коралын җитештерү буенча совет разведкасы тарафыннан чит илләрдә табылган барлык фәнни документлар белән танышырга мөмкинлек бирәләр. Ябык кабинетта яңадан-яңа документлар белән танышырга аны «Черек күл»гә чакыралар. Булганнарына анализ ясаганнан соң, ул, эшне дәвам иттерү өчен, яңаларын соратып ала. Яшерен хатлар Казаннан Мәскәүгә китә. Анда разведчиклар кирәкле документларны табу буенча яңа заданиеләр алалар. Американлыларның Манхэттенда эшләнүче атом проекты турында күп мәгълүматны совет разведчыгы Исхак Әхмәров җитәкчелегендәге төркем җибәрә.

«Уран» программасы

Курчатов Казанда уран бүленеше белән дә шөгыльләнә. Бу проблема бик актуаль була, чөнки бу коралны уйлап табучы, һичшиксез, кешелек дөньясына хуҗа булачак – монысын барысы да бик яхшы аңлый. Бу мәсьәләгә инде союзниклар гына түгел, немецлар да бик якын килгән була.

Казанда Курчатовның башында плутонийны эшкәртү өчен уран-графит концепциясен эшләп бетерү идеясе өлгерә. Ул уран изотопларын диффузион һәм электромагнит бүленеш ысулы белән эшләү турында җентекле план әзерли һәм аны энесе Борис белән тормышка ашыра. Моның өчен алар «Урак һәм Чүкеч» заводында зур тизлекле газ центрифугалары җыя башлыйлар. Алар табигый урандагы изотопларны бүлү һәм уран-235 белән баету өчен кирәк була. Бу ысул Россиядә бүгенгә кадәр кулланыла. Тарихтан билгеле булганча, немецлар Казанны, бигрәк тә «Урак һәм Чүкеч» заводын бик еш фотога төшерәләр. Алар ФАУ-2 ракеталары белән беренче чиратта шушы заводка, 22 нче һәм 16 нчы авиазаводларга, 40 нчы дары заводына, Яшел Үзәндә урнашкан суднолар заводына һөҗүм ясарга планлаштыра. Иң беренче атом станциясе проектын да Курчатов Казанда ясый.

Мәскәүдә

1943 елның 9 гыйнварында Игорь Васильевич Мәскәүгә күченә. «Уран» программасына нигезләнеп, атом проблемасы буенча эшен дәвам иттерә. Ә гаиләсе сугыш беткәнче Казанда яши әле. Аның белән бергә энесе Борис та китә. Ул соңрак күренекле радиохимик, фәннәр докторы, профессор дәрәҗәсенә ирешә, бөтен гомерен шушы лабораториядә эшләп үткәрә. Башка хезмәткәрләр дә аларга иярә. Соңрак 2 номерлы лаборатория нигезендә Атом энергиясе институты ачыла. Аңа Игорь Курчатов исеме бирелә. 1991 елдан ул «Курчатов институты» илкүләм тикшеренү институты дип атала, турыдан-туры Россия хөкүмәтенә буйсына.

Ни кызганыч, «Урак һәм Чүкеч» заводы күптән юк инде. Ахыр чиктә аның урынында «Адмирал» сәүдә үзәге төзелеп, янгыннан хәрабәләр генә утырып калды. Шунысы кызык: заводның бер цехы бүген дә исән. Нәкъ менә шунда сугыш вакытында – Игорь Курчатов, соңрак Гарәфетдин Хисаметдинов эшләгән да инде. Бу бинада хәзер «Пятерочка» кибете урнашкан. Гарәфетдин абый аның һәм КАИның диварына Игорь Курчатов турында истәлек тактасы кую теләге белән янып йөри.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

БИШ БАЛАСЫН ЯЛГЫЗ ҮСТЕРГӘН ИР:

«ӘЛЕ ЯРЫЙ ЧИТ КЕШЕ КЕРТМӘГӘНМЕН»

Яратышып өйләнешә алар. Матур яшьләр. Тормышларын үз куллары белән төзиләр. Кечкенә генә йорт алып, аның янына каралты-курасын, мунчасын салып куялар. Бөтен җирләре җитешкәч, балалар үсеп килгәндә, ишекләрен кайгы җиле шакый.

Кайбыч районының Кече Мәми авылында яшәүче Николай Ворожейкин хатыны савыгыр дип өметләнә. Аның белән бергә биш баласы да шул теләктә була. Әмма Надеждага 46 яшькә кадәр генә яшәргә насыйп булган икән.

– Надежда бер дә сәламәтлегеннән зарланмый иде. Ни булганын үзебез дә аңламадык, – дип искә ала 67 яшьлек Николай. – Ул кичне хатыным сыер саварга дип чыгып киткән иде. Шул чакта кече кызымның ярдәм сорап кычкырганына сискәнеп киттек. Абзарга йөгереп чыксак, Надежда җирдә ята. Сөйләшерлек хәлдә түгел иде. Тизрәк өйгә алып кердек. Табиблар инсульт диделәр. Буа хастаханәсендә алты көн үлем белән көрәште ул. Башына операция ясагач, хәле уңайланып та киткән кебек булды. Күзләрендә яшәү очкыннары пәйда булды. Шул чакта күңелемә җылы йөгерде, өмет барлыкка килде. Биш балабыз хакына исән калыр, дип уйладым. Тик коткарып кала алмадык.

Николай Надежда белән беренче тапкыр очрашуларын әле бүген дә хәтерли. Буа техникумы таныштыра аларны. Егет кызга бер күрүдә гашыйк була. Ике ел очрашып йөргәч, гаилә коралар. Берсе – хисапчы, икенчесе зоотехник булып эшли башлый. Бәхетләренең ташып торган чаклары. Николай бу вакытларны бик сагынып, хисләнеп сөйли.

– Ул чакта очып кына йөрдем мин. Безнең яшь арабыз да – җиде ел бит! Яшь кыз эләктер дә тагын, очма, имеш! Бик акыллы, уңган-булган кызга өйләнгәнемне аңладым. Бик тырыш иде. Бөтен җиребез ялт итеп торды. Өйдән чыгып китүгә үк сагына башлый идем мин аны, – ди Николай.

Күп тә үтми, бер-бер артлы сабыйлар туа башлый. Биш балага гомер бирә алар. Сабыйларны кечкенәдән тормышка өйрәтеп үстерәләр. Әнисез калганда, иң олысы Аннага 24 яшь була. Инде аның үз гаиләсе бар, баласы да туарга өлгергән. 21 яшьлек Татьяна Казанда укый. Әтиләре янында өч бала кала. Николайга – 16, Галинага – 14, Владимирга – 12 яшь.

– Нишләр икән бу Николай, диючеләр күп булды. Берәүләр шешәгә үрелеп күңелен басар дип көтте, икенчеләр кызганып күзәтте. Әмма мин үземне тиз кулга алдым, – ди ул. – Елап утырып булмый. Абзар тулы мал-туар бар. Балаларны кеше итәргә кирәк. Өйрәтә икән ул дөнья! Сыерын да саварга өйрәндем. Кешегә савып бир дип бер әйтеп була, ике әйтсәң. Өченчесендә инде тыңламаска да мөмкиннәр. Мин дә: «Нишләп кеше борчыйм әле», – дидем дә сыер имчәгенә үзем ябыштым. Ул чактагы хисләремне үзем генә беләм. Хатын кадерен тагын бер кат аңладым. Их, мин әйтәм, әгәр исән булса... Үкенечләр булмады үзе. Яратып яшәдем, начар сүзләр әйтмәдем. Авырудан исән калган булса, мин аны тагын да кадерләр идем.

Сыер димәктән, кече уллары Владимирга да эләгә ул. Балалар сөт ярата дип, малны бетермиләр. Алар Казанга чыгып киткәч, сыер урынына абзарга кәҗә кайта.

– Олы кызыма рәхмәт. Ул сеңел-энеләренә әни булды. Казанга барып, аларның артыннан карап йөри алмаячагымны алдан ук әйтеп куйдым. Бу эшләр апаларының җилкәсенә төште. Балаларымның кайда укыганнарын, ничек укыганнарын да белмәдем, – ди Николай.

Кыяр-кыймас кына: «Ник кабат өйләнәсе итмәдегез?» – дип сорыйм. Ә ул исә: «Уйламадым да», – ди.

– Әле ярый йортка чит кеше кертмәгәнмен. Таныштырырга теләүчеләр күп булды. Үземне түгел, биш баланы уйладым. Хәзер барысы да диярлек башлы-күзле булды, инде Владимирны гына өйләндерәсе калды. 26 яшен бәйрәм иттек әле, – дип сөйли 7 оныклы бабай. – Балалар өйгә кайтып керә дә хуҗага әйләнә. Мин исә, рәхәтләнеп, кунак кебек утырам. Бик кадерләп торалар үземне. «Әти, ял ит син», – диләр. Бер дә авыр эш эшләтәселәре килми. Күчтәнәчләрен кызганмыйлар. Җылы якка ял итәргә дә алып бардылар инде. Балык тотарсың дип, көймә дә алып бирделәр.

Николай чуаш милләтеннән булса да, татарчасы бик матур. Кулыннан килмәгән эше юк үзенең. Зоотехник, тракторчы, ташчы, эретеп ябыштыручы, балта остасы, штукатурчы, мич чыгаручы. Әле боларга тагын әллә ничәне өстәргә була. Тормыш сынавын үз иңендә күтәреп, балаларына ятимлек ачысын сиздермичә яшәве – үзе зур хезмәт! Хәер, әҗерен күрә дә инде ул. Әнә урыны түрдә, кадерле үзе! Балалары әти дип өзелеп тора. Күпләр матур картлык тели. Аны да үз кулың белән төзү кирәк. Николай кебек!

Ирем үземә кирәк!

Кияүгә унбер ел элек чыктым. Булачак ирем артымнан өч ел йөрде. Синсез яши алмыйм, диде, башка сүзләр дә кызганмады. Мине генә түгел, хәтта әти-әниемне дә үзенә карата алды. 23 яшенә кадәр шәһәрдә яшәгән кыз авылга килен булып төште.

Тормышыбыз зарланырлык булмады. Каенана белән яшәп җәфаланмадым. Иремнең әти-әнисе безгә аерым йорт җиткереп бирделәр. Шунда матур гына яши башладык. Башта улыбыз, аннан соң кызыбыз туды. Ирем районга йөреп эшли, үзем дә тик ятмадым. Декретта утырганда, торт ясарга өйрәндем. Кешедән заказлар алып эшли башладым. Машинага да утырдым. Акчага да тилмермәдек. «Ватсап» аша иремә килгән хәбәрне укыганчы, барысы да тыныч иде...

...Ул көнне безгә кунаклар килде. Ирләр җыйнаулашып мунчага кереп китте. Иремнең телефоны тәрәзә төбендә калган. Кичке 9лар тирәсендә бертуктаусыз хәбәр килә башлады моңа. Һич кенә тынып тормый. Хатын-кыз йөрәге түзми бит инде, әкрен генә барып карарга булдым. Исем китте: Илгиз Рәсимович дигән кешедән әллә нинди сүзләр килә моңа. «Сагындым. Кайчан киләсең? Чыгып китә алмадыңмы, куяным». Егылыплар китәр идем дә, өй тулы кунак. Тиз генә бу хәбәрләрне үземә күчереп, теге номерны язып алдым. Эчкә корт керде. Бер ир икенчесенә «куяным» дип язсын инде? Юктыр, берәр хатынны ир-ат исеме белән махсус язып куйгандыр, дим. Ничек итеп кунакларны озатканны да, өстәл җыештырганымны да хәтерләмим. Бу көнне иремә бер сүз әйтмәдем.

Иртәгесен башта бер уй. Нишләргә? Әгәр бөтенесен иргә сөйләсәм, тавыш чыгачак. Сабыр итәргә булдым. Иремне читтән генә күзәтим әле, дим. Атна буе ул-бу сизелмәде. Кичләрен дә вакытында кайта, чыгып киткәне дә юк. Ни булды соң бу хәбәр? Тәвәккәлләп, үз әниемә сөйләп карарга булдым. Аның сүзе кыска: «Тапкансың уйлар нәрсә. Әтиеңнең телефонында казынсам, күптән баш бетәр иде. Кирәкмәгән нәрсә карап йөрмә», – ди бу. Әнине тыңлаган кебек итсәм дә, эчем яна гына бит! Әгәр кем беләндер хыянәт итсә? Ник алай итте икән? Үземне матур йөртәм, кеше кызыкмаслык та түгел. Кай җирем ошамый икән? Аптырагач, социаль челтәрдә киңәш сорадым. Андагыларның фикере бер иде: иреңнең сөяркәсе бар.

Бу хәлләрне онытырга да телим, булмый. Күңелдә һаман тынгы юк. Ирем өстемнән йөридер кебек. Җитмәсә, ул да үзгәрде. Соң кайта, кулыннан телефонын төшерми, әле пароль дә куйган. Тик мин кеше паролен генә ача алмаслык хатын түгел шул! Ачтым мин аны. Тәвәккәлләп, теге Илгиз Рәсимовичка матур сүзләр яздым. Әйдә, очрашыйк, дип бер җайлы урын да билгеләдем. Ирем Казанга китте, мин – «свидание»гә. Кафега барып керсәм – каршымда күрше хатыны басып тора! Эшнең нидә икәнен тиз аңлады. Тизрәк китмәкче иде, бирдем кирәген. Иремә башка якын килмәслек иттем мин аны. Рамилгә дә җиткергән бу хәлләрне. Икенче көнне киемнәрен җыеп чыгып бара бу. Ишектән чыгармадым. Чыгарасы булсам, теге Илгиз Рәсимовичны эзләп тә йөрмәс идем мин. Ул да аңлады. Теге хатынга: «Йә туктыйсың, йә иреңә сөйлим, авыл кешеләре алдында оятка калдырам», – дидем. Иремнең гафу үтенүдән башка чарасы калмады.

Бер ел да булмады, күршеләр, йортларын сатып, Чаллыга китеп барды. Ирем дә намазга басты. Мин хәзер бәхетле генә түгел, бик бәхетле. Бу язманы ни өчен язганымны да әйтим әле: ир бирмәк – җан бирмәк. Аерылу, булган тормышны җимерү өчен бер көн җитә! Кешегә бирер ирем юк шул минем.

Исемем редакция өчен генә.
Мөслим районы



Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА:

«ИҖАТКА ҖАЙЛЫ УРЫН КИРӘКМИ»

Люция ӘБЛИЕВА белгечлеге буенча юрист, әмма законлы эш белән иҗатны бәйләп баручы юрист. Бүген интернет киңлекләрендә иң популяр язучыларның берсе дә. Татарстан белән Башкортстанның күп кенә бәйгеләрендә җиңү яулагач, аны язучылар да таныды. Без аның белән әдәбияттагы «сарылык» һәм көнүзәк проблемалар хакында сөйләштек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Сезнең өчен иҗат ул – нәрсә?

– Иҗат минем өчен ул – бер ихтыяҗ. Мин аны көндәлек тормышымны матурлап, ямьләп тора торган бер әйбер итеп кабул итәм. Әгәр инде баштан ук язучы, шагыйрь булам дип уйлаган булсам, югары белем алганда филологияне яки журналистиканы сайлаган булыр идем. Ләкин мин юриспруденцияне сайладым. Хәер, анысы да балачак кызыксынуыннан башланды. Көннәрдән бер көнне мәктәпкә балигъ булмаган балалар эшләре буенча белгеч килде. Ул ханым шундый матур, зифа буйлы һәм бик акыллы иде. Үскәч, аның кебек булам дип ниятләдем. Өстәвенә, гаиләдә бер филолог бар иде инде, төрле һөнәр иясе булса, күңеллерәк бит. Дөрес, иҗат минем белән гел янәшә булды. Чөнки ул рәхәтлек бирә. Мин аның хәтта нәтиҗәсенә дә ул кадәр куанмыйм, язу процессы ошый. Язганда нинди халәттә булуыңны аңлатып та биреп булмый бит. Иҗат ул – турыга язу гына түгел, ул билгеле бер халәткә керү. Әлеге халәт сине аш бүлмәсендә яки концерт караганда биләп алырга мөмкин. Җыеп әйткәндә, иҗатка җайлы урын кирәкми. Бер рәссамнан: «Нишләп иҗат итмисең?» – дип сораганнар ди бит. «Бик иҗат итәр идем дә, остаханәм юк», – ди икән. Остаханә салып бирганнәр, рәссам һаман ясамый икән. Димәк, махсус урында гына түгел хикмәт.

:: Хатын-кызга иҗатта авырмы, җиңелме?

– Ир-ат булмагач, аларга ничек икәнен әйтә алмыйм, миңа хатын-кызга иҗатта җиңелрәктер сыман тоела. Хатын-кыз бит ул бөтен нәрсәгә өлгерергә тырыша, тәгәрмәч өстендәге тиен кебек гел хәрәкәттә. Без сузарга, тартырга яратмыйбыз, мәгълүмат туплауда да җитезрәк. Аннан хатын-кыз тормышның эчендә йөзә, күп нәрсәләрдә сизгеррәк була. Аның мәшәкате дә күбрәк, әмма ул кырыкмаса-кырык проблеманы җиңеп чыгучан, өлгер. Иҗат өчен бу сыйфатлар бик кирәк.

:: Сезнең укучы ул кем?

– Хәзер әйтүе дә авыр. Ник дигәндә, интернет челтәрләре аша укучы географиясе киңәйде. Мин кайвакыт, элек танылган классик язучылар хәзерге заманга кире кайтса, көнләшерләр иде, дип уйлыйм. Чөнки хәзерге заманда әсәр бөтен Җир шарын әйләнеп чыгарга мөмкин. Мин интернет челтәре аша төрле җирләрдә яшәгән милләттәшләребездән хатлар алам. Россиянең барлык төбәгендә дә укыганнарын, кызыксынганнарын беләм. Алар комментарийлар да яза, сатып та ала. Хәзер укырга теләге булган кешегә бөтен шартлар тудырылган. Минем әсәрләремне төрле даирә кешеләре укый. Гади халык та, җитәкчеләрнең укыганнарын да беләм.

:: Укучы бүген язучыдан нинди әсәр көтә?

– Укучыны бер генә йодрыкка сыйдырып булмый. Үзләре дә, зәвыклары да төрле. Һәрбер укучы үзе теләгән әсәрне көтә. Кайчагында бу җәһәттән бәхәс тә чыккалый. Кемдер хәзерге заманга тарихи әсәрләр кирәк дип әйтә, кемдер гаилә турында язуны хуплый. Бөек Ватан сугышы темасын онытырга ярамый, дип әйтүчеләр дә бар. Минемчә, аларның барысы да кирәк. Әле болардан тыш та бик күп темалар бар. Аларны да читкә кагарга ярамый. Укучы исә теләгәнен сайлап ала. Син аңа үз әсәреңне көчләп тага алмыйсың. Детектив яратканы детектив укый инде аның, мелодрамага якын да килми. Башка темалар белән дә шул ук хәл. Халык арасында роман яратучысы да, кыска әсәрләрне генә үз итүчесе дә бар. Язарга кирәк, һәр әсәр үз укучысын барыбер таба.

:: Сезнең әсәр башкаларныкыннан кай ягы белән аерылып тора?

– Мин аны әйтә алмыйм. Үземчә төрле жанрда язам, лирик хикәяләр дә бар, юмор-сатира да. Совет әдәбиятын укып үскән кеше буларак, шул әдәбият миңа тәэсир иткән һәм мин шул юлдан барам төсле тоела. Ничек кенә алсак та, Америка ачып булмый. Гади халыкның авырлыкларын язган язучы да Америка ачмый. Чит ил язучылары бу хакта күп язды инде.

:: Беренче урынга әхлакый тәрбияне куйдыгыз, андыйны укучы үз итәме? Әдәбиятка да «сарылык» кирәк дигән фикергә ничек карыйсыз?

– Әхлакый хикәяләрем хәтсез, аңа фикер белдерүчеләр аз, ләкин укыйлар. Маҗаралы хикәяләргә исә фикерләр бик күп килә. Килен-биана мөнәсәбәтен белдергән әсәрләр дә игътибарсыз калмый. Чөнки аларда – халыкның тормышы, учагы. Учагы булганга, халык аңа утын сала да инде. Ә бу хикәяләр эзсез үтә дип уйламыйм, алар да кешедә фикер тудыра, нәрсә ул яхшы, нәрсә яман икәнне аерырга ярдәм итә. «Сары» әдәбият... Бу турыда аерым сөйләшеп утырып була. Гомумән алганда, мин аңа каршы. Ләкин гел документаль әдәбият кына да укучылар өчен кирәк түгел. Дөрес, ул – үзе бер жанр. Аның да үз укучысы бар. Ләкин ул ничә процентны тәшкил итә соң? 20 процент булсын ди, калганнарның да ихтыяҗын канәгатьләндерергә кирәк бит.

> Язучылар да төрле мохиттә тәрбияләнә. Алар шул йогынтыда иҗат итә. Язучылар географиясенең төрле булуы исә әдәбиятны баета гына.

– Сез укып үскән әдәбият һәм хәзерге. Аерма зурмы?

– Аерма зур дип тә, аерма юк дип тә әйтеп булмый. Әйткәнемчә, без совет әдәбиятын укып үстек. Анда күбрәк совет төзелешенә багышланган, шулай ук Бөек Ватан сугышы турында әсәрләр күп иде. Гомумән алганда, патриотизм темасы үзәктә булды. Без шуның йогынтысында формалаштык. Шуңа безнең буында туган илгә мәхәббәт хисе көчле. Гаилә дә, мәктәп тә шулай тәрбияләде. Һәм ул тәрбияне киләчәк буынга да тапшырырга кирәк. Чөнки ул – минем туган җирем, минем туган илем. Ул гүзәл һәм ул һәрвакыт хаклы. Без яратмасак, аны кем ятарыр? Чит җирләрне яратырбыз, ә ул безгә нәрсә бирер?

:: Әдәбиятның үзгәрүе бәхәссез. Укучы да үзгә. Хәзер татар әдәбиятын да русча укучылар күбәйде. Тагын күпмедер вакыт узар, татарча укучы бөтенләй калмас. Әллә мин ялгышаммы?

– Татар укучысы бөтенләй калмас дип көяләнү, кайгырулар юктан бар булмаган. Ул – билгеле бер анализ, күзәтү нәтиҗәсе. Аны инкарь итеп булмый, ләкин әле вазгыятьне үзгәртеп була дип уйлыйм. Иң әүвәл тел өчен янып йөргән кешеләрне – язучылар, матбугат хезмәткәрләре эшен күрә белергә кирәк. Хөкүмәт тарафыннан дип әйтүем. Һәм шундый милләтпәрвәрләрне күтәрергә кирәк. Андый кешеләргә хәтта матди ярдәм күрсәтү дә яхшы булыр иде. Иң әһәмиятлесе – белгечләр әзерләүне туктатмаска кирәк. Еш кына өйдә татарча сөйләшмәсән, балаларны мәктәп кенә сөйләштерә алмый дигән фикерне ишетергә туры килә. Берара мин үзем дә шулай уйлый идем. Безнең балаларның теле татарча ачылды, өйдә татар мохите булды, алар рус мәктәбен тәмамласа да, урыслашмады. Һәм менә оныгыбыз бар. Аңа да ана телендә тәрбия бирелә. Ләкин соңгы вакытта татар авылларында русча аралашучы балалар барлыкка килгәч, фикерем үзгәрде. Хикмәт авылларда да русча укытуда түгелме икән дип уйлана башладым. Бала белән өйдә татарча сөйләшсәләр дә, урамда, мәктәптә алар үзара русча аралаша. Радио-телевизорда русча тапшырулар тыңлыйлар, карыйлар, интернетта да аларга кирәкле мәгълүмат рус телендә була. Димәк, өйдә генә сөйләшү җитми. Баланың күп вакыты мәктәптә уза. Ул анда нинди телдә аралаша? Ничек карасак та, эш барыбер мәктәпкә килеп терәлә. Анда нинди тел – бала шул телгә өстенлек бирәчәк.

:: Җанисәп нәтиҗәләре көтелгәнчә булдымы? Башкортстанда вазгыять нинди, Татарстанда ни хәлләр?

– Мин бу өлкәдә белгеч түгел. Фикерләрем матбугатта басылган, интернет челтәрләрендә чыккан мәгълүматларга таянып тупланды. Без – Башкортстанның татар төбәгендә туып-үскән кешеләр. Безнең радио-телевидение һәрвакыт башкорт һәм рус телендә сөйләде. Аңа карап телебезне дә, татарлыгыбызны да югалтмадык. Беренчедән, мәктәптә татарча укыдык, икенчедән, өйдә, тирә-якта бер-беребез белән татарча аралаша идек. Ләкин без башка халыкларның әдәбияты, мәдәнияте белән таныштык һәм рухи яктан баедык кына. Без ул телләрне дә өйрәндек. Ләкин безгә аны көчләп тагмадылар. Көчләп такмагач, тел табигый рәвештә өйрәнелә, әчке протест булмый. Ләкин барыбер туган телең туган тел булып кала. Без шәһәргә дә үзебез белән телебезне, мәдәниятебезне, йолаларыбызны алып килдек. Ул безнең белән гомер буе бергә. Аны балаларыбызга да тапшырдык. Балаларыбыз оныкларыбызга тапшыра. Уфада яшәгәндә башкорт, рус дусларыбыз күп булды, үзара өч телдә дә сөйләштек, өч телдә дә җырладык, өч халыкның да биюләрен биедек. Балаларыбыз шуны күреп үсте. Аңа карап башкорт баласы – башкорт, татар баласы – татар, рус баласы рус булудан туктамады. Бу табигый да. Бер милләт тә югалырга тиеш түгел. Бер милләт

Үсешкә илтә торган төп биш кагыйдә

- ✓ Сәламәт тормыш рәвеше алып бар.
- ✓ Белемгә омтыл, кызыксынудан туктама.
- ✓ Бүгенге эшне иртәгә калдырма.
- ✓ Киң күңелле бул.
- ✓ Хыялланудан туктама. Хыял һәрвакыт тормышка аша.

Блиц-сораштыру

– Сезгә ничек кулай: интернеттан укуы, басма матбугатнымы?
– Мин интернет белән басма матбугатны аерып әйтә алмыйм. Интернеттан уку да рәхәт, басма матбугаттан да бизмәдем. Аудиокитапларны яратып тыңлыйм. Ул көндәлек эшләрне эшләргә дә комачауламый. Татар китапларын аудиоформатта күбрәк чыгарсыннар иде.

– Тормышыгызны үзгәртү мөмкинлеге булса, нәрсәне үзгәртер идегез?
– Тормышны үзгәртмәс идем, дип әйтеп булмый. Яши-яши генә бит нәрсәгә юлыгуыңны, нәрсәне югалтуыңны яки табуыңны аңлыйсың. Аннан артка борылып карыйсың да, шул вакытта болай иткән булсам, дип үкенеп тә куясың. Ә инде яшәгән кадәре белән риза мин, шөкер. Тик менә мөмкинлек бирсәләр, чыннан да, кайбер вакыйгаларны үзгәртер идем. Ялгыш адымнан да китеп барган чаклар була, кайберәүләрне, ялгыш юлдан китүен күреп тә, кисәтми калганыңны соң гына аңлыйсың. Акыл соңрак килә шул. Акыл килгәндә, яшьлек киткән була. Икесе янәшә йөрмиләр, кызганычка.

– Яраткан язучыгыз?
– Алар күп, барысын да санап бетереп тә булмый. Исемлек башында, әлбәттә, Габдулла Тукай тора. Аннары Тургеневны, Мопассан әсәрләрен яратып укыйм.

– Тормыш девизыгыз?
– Шигыремнең ике юлы белән җавап бирсәк, болай:
«Бар да үтә, бу халәт тә үтәр,
Сабыр төбе алтын... Килешәм».

хисабына икенче милләт арткан дигән фикерне ишетү миңа авыр. Һәр милләт үзенчә матур. Алар барысы да үз хисабына артсын. Ясалмалык яхшыга илтми. Менә без башкортча аңлыйбыз да, сөйләшәбез дә. Ләкин безнең башкортча сөйләмебез барыбер аларныкы кебек матур түгел. Аның өчен барыбер башкорт булып туарга кирәк.

> Җанисәпнең ялган нәтиҗәләре бер милләткә дә файдалы түгел. Киресенчә, зыян гына. Пропаганда өчен күпме халык акчасы түгелә, ялган язмалар барлыкка килә. Ул ялган язмалар киләчәк буынга мирас булып кала. Алар моны дөреслек дип кабул итеп, тагын шушы ялган юлны дәвам итәчәк.

Җанисәпкә объектив бәя бирелсә, шул нәтиҗәләрдән чыгып, милләтнең киләчәге өчен конкрет эшләр алып барырга була. Бер милләтне икенче милләт хисабына сан ягыннан күбәйткән очракта да, фактик яктан алар кими. Болай дәвам итсә, бөтенләй юкка чыгарга мөмкин ләбаса. Чөнки төп милләткә игътибар бетә, проблемалар вакытында хәл ителмичә кала. Аның шул яклары да бар бит әле. Шуңа күрә һәр милләт үзен саклысын, һәр милләткә үсү өчен шартлар тудырылсын иде. Күп очракта болар үзебездән дә тора.

:: Хәзерге вакытта нинди әсәр язасыз?
– Башланган берничә хикәям бар, шулар белән эшлим. Күңел халәтемә кайсы туры килә, шунысына утырам. Ашыгып яза торган гадәтем юк. Рәхәтлек бирә торган минутлар кичерәсем килә икән, хикәягә алынам. Шигырь инде ул көн дә туа. Аның кайсы теркәлә, кайсы теркәлми дә кала. Лаеклы ялда булгач, иҗат тормышымда күбрәк урын били.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

АСИЯ ЮНЫСОВА

МАДАМ БОВАРИ

< Дәвамы. Башы 27 гыйнвар санында

Мадам Бовари! Китап төреп торучы Талия апа сүзеннән ябышты да калды шушы кушамат. Типографиянең экспедиция дигән җирендә эшлиләр алар. Әзер китапларны, газета-журналларны төреп, озатып торалар. Мондагы халык та укымышлы. Газета-китап ише әйбернең дә брагы чыга. Әмма укымаслык түгел. Укыйлар хатыннар. Талия апа да кайчандыр Флоберның «Госпажа Бовари» дигән романын укыган икән ләбаса. Менә белеме ярады. Мәүлия кушаматлы булды. Кушаматның ниндие булмас. Китапны үзе дә табып укыды. Кушаматы белән килеште Мәүлия: ул – чыннан да, Мадам Бовари!

Бовари мәхәббәт иясен таба белгән. Мәүлиягә күренми әле монда. Хатыны үлгән ирләрне юри димләгән булып котыртулары да туйдырды. Бу уенны үзе башлаган иде дә бит. Кабатлана торгач, тәме китә икән. Шуңа күрә Гөлчирәнең газеттагы некрологларны юри мәгънә салып укуына ачуы чыкты.

сезне белгән берәү бирде. Кем икәне секрет. Ул сине яхшы белә, мактады. Душевный хатын дип әйтте. Әй, апасы, монда кара әле, без «ял иткән» җирдә иң җитмәгән әйбер дә шул бит.

Мин үзем начар егет түгел. Не за что утырам. Беренче хатта ук статьямны әйтеп тормыйм. Ну, Мәүлия-җан, җавап яз син миңа. Үкенмәссең. Фотоңны җибәрсәң, күкрәк кесәмдә генә йөртер идем. Үзем дә салырмын фотканы. Монда ул нәрсәне бик тиз генә эшләтеп булмый. Почмак саен фотосалон юк, диюем. Син аңлыйсың инде!

Кайнар сәлам белән Рахман дип белерсез».

Сезе белән сине буталган, өтере, ноктасы югалган хатны Мәүлия кат-кат укыды. Адрес бирүче кем булыр икән дип тә уйламады. Күзе һаман бер җөмләгә туктады: «Фотоңны күкрәк кесәмдә генә йөртер идем...» Мәүлия серле сүзләр алып килгән конвертны кат-кат әйләндерде. Конверт тышындагы «Почтальон агай, быстро шагай» дигән язуны укып елмайды.

– Хафаланмасаң да була, дустым. Менә дигән кешем бар минем.

– Кем?

– Кем симәннең кече улы. Белми торыгыз әле бу юлы. Сәгате җиткәч, әйтермен.

– Эрләмәгән, сукмаган – кызым, сиңа ыштанлык, дигәндәй, бер өметсез хыялыңдыр әле тагын.

– Түгел, иртәгә үк хатларын алып килеп укытырмын. Озакка командировкага китте әле ул.

– Менә-менә! Командировкадамыни әле... Төрмәдә түгелме тагын? Аннан сырлап-сырлап хат язарга яраталар.

Өстенә басты бит каһәрең. Серле адресны хат килеп төшкәч, Мәүлиянең үзенең дә йөрәге иң әүвәл рәхәт сулкылдап алган иде. Әмма хатны ачып укыгач, конверт тышындагы адресның мәгънәсенә бик тиз төшенде. Гөлчирәнең, әле конвертны күрмичә дә нәкъ өстенә басуына үртәлеп, Мәүлия елап җибәрде:

– Түгел! Син нәрсә, әллә мине юньле кеше карамаслык карачкы дип беләсеңме? Кай җирем кешедән ким?

– Юк, юк, җаным, тынычлан. Син безнең арада үзең бер, сиңдәгедәй куе бөдрә чәчләр артистларда да юк. Сәхнәдә җырлап йөргән җырчылар синең каршыда чыпчык кына. И, и-и, Мәүлия бәгырькәем. Без барыбыз да, теге театрда әйтмешли, сиңдәй-миңдәй бозау. Безнең кимлек бер инде: байлык юк. Китапта гына ул урамда барганда миллионер егеткә бәрелеп, ярлы кызы бәхет таба. Гади генә бәхет тә ярар иде безгә. Шофер булса да, эчми торганы. Үзе белеп күлмәген, оекбашын алыштырып кия торганы. Үтүкләмәсә дә... Нәрсә елап торасың инде?! Йә сәнә. Дөресен әйттеммени соң? Өстенә бастыммыни? Төрмәдә булса ни соң! Хәзер буй-сынлы, егәрле ирләрнең бөтенесе төрмәдә. Беркөн газетада күрдем әле. Камал театры артистлары төрмәгә спектакль күрсәтергә барганнар да шуннан фотосын басканнар. Исләрем-акылларым китте. Тамаша залы тулы тупырдаган тайдай егетләр.

Рахманның хатын бергәләп укыдылар. Җавап язарга да күндерделәр. «Яз әле син, яз. Кайчан кайта әле ул? Аннары уйларсың тагы... Син хыялыйга хат алышу да – бер дәва», – дип, төпле акыллы Талия апа Мәүлия өчен хәл итте дә куйды.

«Исәнмесез, сез ки минем өчен таныш булмаган Мәүлия. Миңа сезнең адресны

Җавап язарга өлгергәнче, хатның икенчесе килеп җитте. Хат эчендә фото бар иде. Фотода күкрәк тиңентен шәрә ир кеше. Кулларын чалыштырып, гәүдәсен кочаклаган. Кырылган башында керпе чәчләре шактый куерган инде. Күз карашы кыеп карый торган. Бу Рахман бер дә акылсыз кешегә охшамаган. Аның кебекләр сугыш вакытында геройлык кылсалар, тыныч (хәер, кая ул тынычлык!) заманда кемнедер яклап пычак астына керәләр.

Мәүлия аны герой итеп кабул итте. Хәтта өченчеме-дүртенчеме хатында Рахман зонага эләгүнең сәбәбен «чистосердечно» язгач та, ул Мәүлия өчен бүрек каракдары кәкре каенга терәткән әрекмәнбаш түгел, бәлки, үз өстенә гаеп алып, бүтәннәрне бәладән коткарган Алып батыр булып калды.

Җавап хатларында Мәүлия аңа үз тормышын түкми-чәчми сөйләде. Әз акчага кысан көнкүрешен, малай укытуын, җыр яратуын, назга сусавын... Бәлки бер күрмәгән кешегә бу кадәр ачылып китәсе дә түгелдер. Ләкин... Кәгазьдән дә түзем ни бар. Әле ырудан калмаган яшь хатынның – ул үзенә бик яшь тоела – күңеленә тәңгәл ярын табарга омтылышы гаепмени? Кабырчыгыны ачып, үз йөзеңне күрсәтми генә җавап «биюе»нә исәп тоту дөрес тә түгел. Ачылды, Мәүлия ачылды. Аңа инде Рахманны ярата ук кебек тоела башлады.

Төрмә ишеге ачылыр сәгатьне алар зонаның икесе ике ягында көннәрне берәмтекләп санап көттеләр. Хәзер инде Мәүлия кибетләрнең ирләр киеме сатыла торган бүлекләренә дә кагыла. Юк акчасын бар итеп, Рахманга кием-салым да сатып алды. Вак-төякне инде. Зурысына акча кая ди? Төннәрен хыял дөньясында Рахманның татуировкалы зур куллары Мәүлиянең битләреннән назлап сыйпый. Алар, имеш, диңгез буена ялга китәләр... Рахман биек-биек тауларга Мәүлиясен күтәреп кенә менә... Ә диңгезгә алар үз машиналарында гына барганнар икән. Әй, гел-гел диңгез буена йөрү дә туйдыра. Инде хатын хыялында Рахман белән Мәүлия Мишә буенда өй салырга керешәләр. Мәүлия төне буе кирпеч бәясен чутлый, такта юллый, җиһаз сайлый... Иртәгәсен төнге мәшәкате сәбәпле юньләп йокы күрмәгән килеш эшкә китә. Төнге хыялларын исә Рахман хәере белән кайткач булачак тормыш рәвеше итебрәк колония адресына озын хатлар итеп яза:

«И Рахман, җанымның адашкан кисәгедер лә син. Кайтыр көннәреңне санап, календарьда һәр үткән числоны сызып барам... Син үзеңне балта тотып эшлим дигәнсең. Хәзерге заманда бик кирәкле һөнәрең бар икән, бәгырь генәм. Хәзер бит бөтен кеше йорт салып җенләнә. Хәле барлар. Үз йортның белән яшәү рәхәт булыр иде. Син дә кайтып, әйбәт эшкә урнашсаң, әллә без дә берәр матур өйгә тырышып карар идек микән? Тәрәз каршына ясмин куагы утыртып, шуның хуш исен иснәргә хыялланам. Эштәгеләр белән Сембергә сәяхәткә барган идек. Анда урамнарга чыршы да, тирәк тә түгел, ясмин куагы тезеп утыртканнар. Исләр китмәле... Төзү материалы табып була хәзер. Кулы белгән кеше осталар ялламыйча да булдырып чыга ала. Менә нинди синең Мәүлияң. Тумаган тайның билен сындыра торган хыялый хатын. Минем хыялда әле ул өйнең бакчасында бер бәләкәй кыз да йөгереп йөри... Эштәгеләр Мәүлиянең бу юләрләнүе озаккарак китүенә, көткәненең әллә кем түгел, бәлки «төрмә кошы» булуына көенәләр. Төрмәгә киткәнче гел әйбәт кенә булган кеше дә, аннан бозылып, үзгәреп, җенлегә әйләнеп кайта ди бит. Мәүлия үзе генә исе китмәгәндәй көлә. Төннәрен гел «төрмә кошы»н уйлап саташып чыгулары хакында хәбәр бирми. «Кайткач күз күрер, ахирәтләр. Миңа аның бүгенгесе кыйммәт. Теш сызлаганда уйлар кешең дә булмаса, бүген ятып үлешле».

Рахманнан хат бар. «Мәүлия-җан, чәеңне куя тор, 30 ноябрьдә миңа капка ачыла», – дип тәгәлләнгән ул хат Мәүлиянең хәрәкәтләрен тизләтте, итәк астына җил үтеп, этеп йөртә диярсең. Ул өен Рахман кайту көненә ни рәвешләргә бизәсен әллә кайчан ук хыялланып куйган иде инде. Ялга каршы авылына кайтып китте. Аннан казның түш мамыгыннан тутырылган ике мендәр сатып алып килде. Яңа туган бәби өчен генә тотарлык ул мендәрләргә башын куеп-куеп карады. Бер мендәрдә үзенен башы, икенчесендә – Рахманныкы.

Мендәрләргә карап-карап йөрде дә, бер кичне киергесен табып, мендәр тышы чигәргә утырды. Аның бит әле бу яшенә җитеп, туйлап, бирнәләп, кияүгә чыкканы юк. Шуны уйлап, Мәүлия үзенә бирнә әзерлисе итте. Әзере юк сыман, ал чәчәкле зәңгәр сатин алып, юрган сырды. Идәндәге паласны алыштырды. Яңа пәрдәләр элде. Югыйсә Рахман үзгәрешне сизмәс тә. Аның бит Мәүлия өендә булганы юк. Хәтта савыт-саба да кузгалды. Юшкын каплаган чәйнек урынына яңасы алынды, кеше килгәндә генә тота торган чынаяклар шкафның өске киштәсеннән төште.

Азык-төлек, тәм-томга да чират җитте. Һәр төрле ризыкны Мәүлия күпләбрәк алып куйды. Пешерәсен пешерде. Хәзер бозылмый. Бер таба гөбәдия, алып кереп җылытканны гына көтеп, балконда утыра, койкасын да пешереп чыгарып куйган. Рахман кайткач, вак-төяк мәшәкать белән иң изге эштән – яратышу, бер-береңә якынаюдан буленмәс өчен алдан ук күрелде бу хәстәр.

Рахманның ишектән керер сәгатенә кадәр үк уйланылган иде. Ишек төбендә аны яңа башмаклар көтә, ванна бүлмәсендә пижама. Төрмәдән сон ванна гына аз булыр. Чиста киемнәр тоттырып да мунчага җибәрер ул аны. Төрмәнең бөтен әшәкесен ир шунда калдырып кайтыр. Мунчаны уйлагач, базарга чыгып, каен себеркесе алып керде. Барысы да булды дигәндә генә, кырыну әсбабы юклыгы исенә төште. Монысына хатын аптырабрак калды. Яхшы әсбаплар шактый кыйммәт икән. Акчасы саекты бит әле. Җаен тапты тагын. «Җиллет» җыелмасы алды – бер тапкыр тоткач, ташлый торганнарын.

Дәвамы бар >

СУ ЭЧЕГЕЗ

- **Иртән уянгач.** Эчке органнарны су уятып җибәрәчәк.
- **Тренировкадан соң.** Йөрәк тибешен нормага китерәчәк.
- **Ашарга 30 минут кала.** Ашказаны системасын әзерләячәк.
- **Йокы алдыннан.** Төнлә организмда су кимүдән саклаячак.
- **Ваннага керер алдыннан.** Кан басымын төшерәчәк.
- **Авыруганда.** Организмның су ресурсларын нормага китерәчәк.
- **Арыганда.** Көч бирәчәк.

Әз-мәз мәзәк

– Әти, ә динозаврлар тәмлеме?
– Дәү әниеңнән сора.

* * *

Акыллы гаджет, акыллы йорт, акыллы телефон, акыллы сәгать бар хәзер. Акыллы кешеләр кая китте соң?

* * *

Нинди тормыш бу?! Ни хатын юк! Ни сөяркә юк! Икесе дә командировкада!

* * *

– Матурым, ашадыңмы? Мин әзерләгән ризык ошадымы?
– Әйе. Аеруча ипи.

* * *

Бүген төшемдә көн буе эшләдем. Бу көн өчен кем түләр?

* * *

Тропик җирлектә экскурсовод:
– Әгәр елганың теге яры күренә икән, димәк, тиздән яңгыр явачак.
– Ә күренмәсә?
– Димәк, яңгыр инде хәзер үк ява.

* * *

– Көн саен яңа урыннар, яңа кешеләр белән очрашам…
– Командировкаларга йөрисеңме?
– Юк. Склероз.

* * *

Күпчелек кешеләр акыллы. Әмма миңа ни өчендер гел азчылык очрый.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: сатлыкҗан, чыбыркы, бабай, Буа, матдә, Наил, Ита, Ола, Пыяла, Ларан, йодрык, тенор, Әпипә, Ока, горур, Бол, Бад, Адель, орчык, Спарк, Марина, Ри, уха, тубал, Атлас, би, за, Лиана, ки, гайре, оскыту, автор, Рамил, Анапа, абыстай, йокылык.

Вертикаль: Сарманай, Алабуга, олпат, Илдар, риал, пычрак, си, кабымлык, арка, Әбелханова, Арбат, Пол, астма, диафильм, коин, әйбәт, аң, Кырлай, алхәбәр, бит, По, ыргак, уймак, ортодонт, лаек, Рауза, Анна, бай, чыра, ычкындыру, килмешәк.



Беләсең килсә...

1 Мәйданы буенча кайсы ил зуррак?
а) Италия;
б) Польша;
в) Төрекмәнстан.

2 Әлеге шәхес Әлки районы Яңа Камка авылында туган:
а) Нәби Дәүли;
б) Хәсән Сарьян;
в) Мостафа Ногман.

3 Алексей Пажитнов нәрсә уйлап тапкан?
а) аклы-каралы телевизор;
б) «Тетрис» уены;
в) пенициллин.

4 «Бриллиантовая рука» фильмында Нонна Мордюкова уйнаган управдом апаның фамилиясе нинди?
а) Плющ;
б) Плащ;
в) Прыщ.

Җаваплар: 1. в); 2. а); 3. б); 4. а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 216

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+